АВЫЛНЫ САКЛАУЧЫЛАР

Чистай районының Исләй авылы халкын өмет яшәтә

> 6

КАЗАН АЛТЫНЫ

Хәзинә табылырмы?

> 16

ЗИФА КАДЫЙРОВА:

«Кадыйрова яман байдыр, диләр»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 151 (28924) | Җомга | 14 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«Татар-информ» / Михаил Захаров

МЫЛТЫК һӘМ ТУГРЫЛЫК

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ ХӘРБИ ӨЙРӘНҮЛӘР УЗУЧЫЛАРНЫҢ ХӘЛЕН БЕЛЕШТЕ

Төз ату гына җитми, бер-береңне саклый белергә дә кирәк. Өлешчә мобилизациягә эләгеп, кулына кабат корал тотарга мәҗбүр булган ир-егетләрне Казан читендә урнашкан полигонда әнә шуңа өйрәтәләр. Октябрь аена кергәннән бирле биредә көн саен йөзләгән кеше ату һәм яту, саклану һәм саклау тәртибен искә төшерә. Соңгысына аеруча игътибар бирелгәнгә без дә инандык. Егетләрнең исән-сау кайтуларын көтәләр.

> 5

Ишетми калмагыз

Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге чит ил агенты булып саналучы затларга бирелмәячәк. Тиешле Указны Президент Рөстәм Миңнеханов имзалады. Премиягә дәгъва кылучы кандидатлар, гариза биргәндә, чит ил агентлары реестрыннан үзләренең әлеге статуска ия булмавын раслый торган мәгълүмат тапшырырга тиеш. Кандидат яки билгеле бер коллектив әгъзасы бүләккә лаек булып, премияне кулына алганчы чит ил агенты буларак игълан ителсә, аны лауреатлар арасыннан төшереп калдырачаклар. Тиешле указ бу елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Киләсе елда Россиядә эшләмәүче пенсионерларның пенсияләре инфляциядән югары булачак. Бу хакта Россиянең хезмәт һәм социаль яклау министры урынбасары Андрей Пуд хәбәр итте. «2023 елның 1 гыйнварыннан һәм 2024 елда эшләмәүче пенсионерларның иминият пенсияләре күләмен уртача 1 мең сумга арттырырга мөмкин булачак», – диде ул.
Сүз уңаеннан, Татарстанда пенсиянең уртача күләме 19 мең сумнан артты. Шул ук вакытта керемнәре пенсионерның яшәү минимумыннан түбәнрәк булган өлкән яшьтәге кешеләргә федераль бюджеттан 10175 сум өстәп түләнә. Республикада мондый ярдәмне 62 меңнән артык кеше ала.

Татарстанда талпан кадалудан зыян күрүчеләр саны арткан. Медицина оешмаларына шул сәбәп белән барлыгы 10 меңләп кеше мөрәҗәгать иткән. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, бу – 2021 ел күрсәткеченнән 1,6 тапкыр артыграк дигән сүз. Мөрәҗәгатьләрнең иң күбе – Казан (2215) һәм Чаллыда (1440).
Искәртеп узабыз: талпаннарның активлык чоры апрель һәм октябрь айларына туры килә. Талпан кадалса, аны алу, вируслы энцефалитка тикшерү өчен, кичекмәстән медицина оешмасына мөрәҗәгать итәргә кирәк, ди белгечләр.

Россиядә яшәүчеләрнең һәр икенчесе (сораштыруда катнашучыларның 52 проценты), быел Яңа ел чараларын уздырмаска кирәк, дигән фикердә. «Superjob» порталы уздырган сораштыру нәтиҗәләре шул турыда сөйли. Катнашучыларның 29 проценты бу фикер белән килешми, ә 29 проценты җавап бирергә кыенсынган. Шунысы кызык: бәйрәм чараларының кирәк булмавын белдереп, күбесенчә 45 яшьтән өлкәнрәкләр тавыш биргән. 35–44 яшьлекләр арасында бу фикерне кешеләрнең 53 проценты хуплаган.

Инвалидлар үнкөнлеге алдыннан Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы «кайнар линия» ачты. Бирегә мөрәҗәгать итеп, сораулар бирергә һәм тәкъдимнәр җиткерергә мөмкин. (843) 557-20-49 номерына дүшәмбедән пәнҗешәмбегә кадәр – 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга көнне 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр шалтыратырга була. «Кайнар линия» 7 ноябрьгә кадәр эшли.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Шәһәрнең генераль планында яңа торак пункт – Биклән урманчылыгы бистәсен төзү каралган. Аның мәйданы 17 га тәшкил итә. Районның Төзелеш һәм архитектура идарәсе башлыгы Алсу Әхмәдиева әйтүенчә, генераль планга үзгәрешләр кертү буенча эшләр башлану федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдәге яңа чараларга да бәйле. Бу – «Идел» М7 федераль автомобиль юлын төзү, Кама сәнәгать кластерын үстерү максатларында «Алабуга» предприятиесенең индустриаль паркын урнаштыру, «ТАИФ-НК» объектларын шәһәр чикләренә кертү һәм башка проектларга бәйле.
(e-nkama.ru)

Аксубай

«Урманны саклыйк» бөтенроссия акциясе кысасында районда 10 меңгә якын үсенте утырттылар. Бу эшне өч мәйданчыкта оештырдылар. Ибрай участок урманчылыгында кырыкка якын кеше җыелды. Алар 1,9 гектар мәйданда дүрт меңгә якын каен үсентесе һәм шуның кадәр үк корычагач утырттылар. Чабаксар участок урманчылыгында Урмандеево авыл җирлеге хезмәткәрләре, Савгач, Урмандеево мәдәният йортлары хезмәткәрләре эшләде. Яңа Думада (Аксубай участок урманчылыгында) Яңа Кармәт авыл җирлеге, мәктәп һәм мәдәният йорты хезмәткәрләре җирле мәчет һәм халык катнашында авыл территориясен яшелләндерде.
(«Авыл таңнары»)

Мамадыш

«Квантум» балалар иҗат үзәге хезмәткәре Радик Василов Эльбруска Мамадыш районы һәм иҗат үзәгенең әләмнәрен алып менде. «Хәзер мин Кабарда-Балкар Республикасының башкаласы Нальчикта. Европаның иң биек ноктасы булган Эльбруска менү күптәнге хыялым иде», – диде ул. Радик, сәяхәтен дәвам иттереп, Чечня, Дагыстан һәм Төньяк Осетияне күреп кайтырга хыяллана.
(«Нократ»)

Зәй

Ринат Фәрдиев исемендәге татар гимназиясе укучылары Тимур Заһитов белән очрашты. Контракт буенча хәрби хезмәт узучы Тимур, Украинада махсус хәрби операциядә катнашканда, гимназиянең башлангыч сыйныф укучысы Наил Габдрахмановтан хат алган. Ялга кайткан егет кайчандыр үзе белем алган уку йортына килде. Гимназиядә батыр егет Наилгә десантчылар әләме һәм тельняшка бүләк итте, укучыларның сорауларына җавап бирде. «Интернет челтәрендәге барлык хәбәрләр дә дөрес үк түгел. Акыллы булыгыз, яхшы укыгыз. Безне шулай рухландырып торыгыз», – диде «Батырлык ордены» белән бүләкләнгән якташыбыз.
(«Зәй офыклары»)

tatarstan.ru

ГАЗ КИЛЕШҮЕ

Президент Рөстәм Миңнеханов «Россия энергетика атналыгы-2022» халыкара форумында катнашты. Анда «Газпром» ГАҖ идарә рәисе Алексей Миллер белән алар 2025 ел азагына кадәр төбәкне газ белән тәэмин итү һәм газлаштыру үсеше программасын имзаладылар. Безнең республика белән мондый документ беренче тапкыр төзелде.

Әлеге программа буенча Әгерҗе, Азнакай, Әлмәт, Әтнә, Югары Ослан һәм Яшел Үзән районнарында урнашкан тугыз авыл, шулай ук Казаннан көнбатышка таба «Зур Яшел Үзән» проекты территориясенә газ киләчәк. Шул итеп 7,4 мең йорт һәм 13 котельный «зәңгәр ягулык» белән тәэмин ителәчәк. Программаны гамәлгә ашыру кысасында «Газпром» бистәләр арасында 11 газүткәргеч төзеячәк. Моннан тыш, Казанда, Әгерҗе, Әлмәт, Биектау, Яшел Үзән, Лаеш, Лениногорск, Минзәлә һәм Саба районнарында газ тоташтыру өчен шартлар булдырылачак. Моның өчен «Газпром» берничә станцияне төзекләндерәчәк, ике газүткәргеч төзеячәк. Яңа кулланучыларны тоташтыру өчен шартлар тудырылачак.

Рөстәм Миңнеханов белән Алексей Миллер Татарстанда табигый газны мотор ягулыгы рәвешендә куллануны арттыру турында да килешү имзаладылар. «Газпром» яңа газ заправкасы станцияләрен төзү белән шөгыльләнәчәк. Сүз уңаеннан, Татарстанда әлеге компаниянең газ тутыру челтәрендә 25 объект исәпләнә. Республика Хөкүмәте төбәк транспортын табигый газга күчерү өстендә эшләячәк.

Татарстанга кагылышлы тагын бер килешү «Росатом» белән Казан дәүләт энергетика университеты арасында имзаланды. Аны Президент Рөстәм Миңнеханов алдында дәүләт корпорациясе генераль директоры Алексей Лихачев һәм башкала вузы ректоры Эдвард Габдуллаҗанов имзалады.

Мәскәүдә узган форумда Татарстан Президенты Россиянең энергетика министры Николай Шульгинов белән дә очрашты. Очрашуда энергия җитештерү һәм нефть чыгару турында фикер алыштылар.

Киләчәк юлы

Такыр да булсын, имин дә булсын. Казанда узучы «Юл 2022» халыкара махсуслаштырылган күргәзмәсендә барыбызга да кагылган мәсьәләләр турында фикер алышалар. Юлны ничек һәм нәрсә белән салырга, тизлек арткан заманда иминлекне ничек сакларга? Төп сораулар әнә шуннан гыйбарәт.

«Казан Экспо»га юл техникасы җитештерүче 40ка якын компания вәкилләре җыелган. Шулардан 30дан артыгы – Россия вәкилләре. Алар үзара хезмәттәшлек, шул исәптән, кирәк җиһазларны үзебездә җитештерү турында фикер алыша. Монысы – көн кадагында. «Безнең төп максат – кешенең тормыш сыйфатын күтәрү. Бу – яшәү һәм эшләү, сәламәтлек һәм ял итү өчен уңайлы шартлар тудыру. Автомобиль юллары һәм автомобиль транспорты булмаса, бүген заманча тормышны күз алдына да китереп булмый. Икътисади үсеш юлларның сыйфаты һәм иминлегенә бәйле», – диде ачылу тантанасында Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин.

Соңгы елларда Татарстанда моңарчы күрелмәгән күләмдә юл эшләре башкарыла. Мәскәү белән Казан арасын тизйөрешле М12 юлы тоташтырачак. М7нең Чаллы һәм Түбән Каманы урап уза торган өлеше дә булачак. Бу әле иң зурлары гына. «Автомобиль юллары челтәрен үстермичә, авыл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм башка өлкәләрдә өстенлекле илкүләм проектларны тормышка ашыру мөмкин түгел. Безнең уртак бурычыбыз – юлларыбызның елдан-ел сыйфатлырак һәм иминрәк булуы», – диде ул.

Әмма акча белән теләк кенә җитми. Татарстанның юл төзелеше комплексында 10 меңнән артык белгеч эшли, һәм алар кулланган техниканың күпчелеге чит илдә җитештерелгән. «Хәзер төп бурыч – Россиянең сәяси, икътисади, логистик һәм технологик бәйсезлеген тәэмин итү», – дип белдерде Алексей Песошин «Россиядә эшләнгән» конференциясендә чыгыш ясаганда. Аның сүзләренә караганда, Татарстанда машина төзелеше комплексының кирәкле әйберләрне җитештерә алырлык мөмкинлеге бар. Моны ул, әлбәттә, башка төбәкләрдән килгән кунаклар ишетсен өчен әйтте. Үзебезнекеләргә дә башкалар өлгергәнче бу эшкә тотынырга кирәк.

Күргәзмә кысасында юл иминлеге турында да фикер алыштылар. Югары технологияләр һәм фән казанышлары, инновацияләр һәм инвестиция күрсәткечләре мөһим. Әмма аларның халык тормышына, шул исәптән иминлегенә ничек йогынты ясавы тагын да мөһимрәк. Алексей Песошин сүзләренчә, төп бурычларның берсе – юлда һәлак булучылар санын киметү. Соңгы 5 елда күңелсез саннар, 2017 ел белән чагыштырганда, 26,5 процентка кимегән. Әмма проблема әле дә көн кадагында кала бирә.

ЯРДӘМ КАБАТ ЯНӘШӘ

Татарстанда #БезБергә акциясе кысасында янәдән «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» хәрәкәте эшли башлады. Волонтерлар мобилизацияләнгән кешеләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итәчәк.

Моның өчен республика буйлап махсус штаблар ачылыр дип көтелә. Әлеге штабларга хәрбиләр һәм аларның гаиләләре өчен кирәк-яраклар алып килергә мөмкин булачак. Моннан тыш, ихтыяҗы булган һәркемнең «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» волонтерларына мөрәҗәгать итеп, юридик яисә психологик ярдәм алу мөмкинлеге дә бар.

– Безнең хәрәкәт волонтерлары коронавирус пандемиясе чорында бик актив эшләде, республика халкына ярдәм итте. Һәм менә хәзер без кабаттан берләшергә кирәк булуын аңладык. Безнең волонтерлар мобилизацияләнгән кешеләргә һәм аларның гаиләләренә төрле юнәлешләрдә ярдәм күрсәтәчәк. Ярдәм төрләре алга таба тагын да киңәйтеләчәк, – дип аңлатты әлеге хәрәкәтнең координаторы Тимур Сафин.

«Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» хәрәкәтенә теләгән һәркем кушыла ала. Моның берничә юлы бар: хәрәкәтнең рәсми счетына акча күчерергә, расланган исемлек нигезендә гуманитар ярдәм җыярга мөмкин. Шулай ук проектка волонтер һәм партнер буларак катнашучыларны да көтәләр. Хәтта ки мобилизацияләнгән кешеләрнең йорт хайваннарын вакытлыча карап торырга мөмкин. Тулырак мәгълүмат белән рәсми сайтларында танышып була.

Ярдәм сорап һәм ярдәм тәкъдим итеп, 8 (800) 350-02-16 номеры буенча «кайнар линия» телефонына шалтыратырга мөмкин. Ул көн саен 9:00 сәгатьтән алып 19:00 сәгатькә кадәр эшли. Гаризаларны хәрәкәттә катнашучылар эшкәртәчәк һәм аларның үтәлешен контрольдә тотачак.

Татарстанның «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» хәрәкәте 2020 елның язында катлаулы хәлдә калган кешеләргә ярдәм күрсәтү өчен оештырылды. Ул эре предприятие җитәкчеләрен, җәмгать эшлеклеләрен, волонтерларны, хәйриячеләрне һәм, гомумән, башкаларның язмышына битараф булмаган барлык кешеләрне берләштерә.

Теманың дәвамы 15 нче биттә >

ПРЕЗИДЕНТ ӘЙТӘЧӘК

20 октябрьдә Татарстан Президенты Дәүләт Советына еллык Юлламасын җиткерәчәк. Әлеге чара Салих Сәйдәшев исемендәге Зур Дәүләт концертлар залында булачак. Шул ук көнне парламент депутатлары тагын бер утырыш уздырачак. Дәүләт Советы Президиумы утырышында әнә шундый карар кабул иттеләр.

Беренче утырышта депутатлар Президентны тыңласа, икенчесенең көн тәртибенә 11 мәсьәлә кертелгән. Алар арасында 8 – республика һәм 2 федераль закон проектлары. Төп мәсьәлә – 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан бюджеты турындагы закон проекты. Аны комитет утырышларында, район һәм шәһәр вәкилләре белән республика киңәшмәсендә һәм парламент тыңлауларында тикшерделәр. «Бюджет кытлыгы булуга карамастан, республиканың төп финанс законының социаль юнәлеше сакланды. Моннан тыш, гамәлдәге барлык дәүләт программаларын финанслау каралган», – диде закон проекты хакында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Бюджет катлаулы геосәяси һәм икътисади шартларда туплана. Барлык үзгәрешләрне һәм таләпләрне исәпкә алып төзелә. Тулаем алганда, 2023 елга консолидацияләнгән бюджетның керем өлеше – 394 млрд сум, ә чыгым өлеше 422 млрд сум булыр дип фаразлана. Шулай итеп дефицит 27 млрд сум тәшкил итәчәк. 2023 елга республика бюджеты керемнәр буенча – 333,9 млрд сум, чыгымнар буенча 361 млрд сум булыр дип фаразлана. Дефицит 27,1 млрд сум тәшкил итәчәк. Бөтен дефицит республика бюджетында тупланган. Муниципаль районнарның, шәһәр округларының һәм җирлекләрнең бюджетлары дефицитсыз дип фаразлана.

Республика бюджеты белән бер үк вакытта 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 елларның план чорына Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турындагы закон проекты да тикшерелә, ул шулай ук беренче укылышта карау өчен киләсе утырышның көн тәртибенә кертелгән. Моннан тыш, депутатлар кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү, халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәтлек саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу, Татарстан Җир, Экология һәм Гаилә кодексларына үзгәрешләр кертү турындагы закон проектларын тикшерәчәк. Көн тәртибенә башка мәсьәләләр дә кертелергә мөмкин.

Гадел булсын!

Республиканың төрле районнарындагы суд участокларына сайланган 11 җәмәгать судьясы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кулыннан таныклык алды.

Җәмәгать судьялары тарафыннан карала торган эшләр саны ел саен арта бара. 2021 елда алар 630 меңнән артык эш һәм материалны тикшерсә, 2022 елның алты аенда бу күрсәткеч 357 меңнән артып киткән. Фәрит Мөхәммәтшин алар башкарган эшнең әһәмияткә ийтеп, бер мәсьәләгә аерым тукталды. Ул аерылышуга бәйле эшләргә аерым игътибар бирергә, аларны татулаштыру юлын табу хокукын ешрак кулланырга киңәш итте. Аның фикеренчә, мондый эшләрне караганда ир белән хатын икесе дә судка килсә, нәтиҗәсе яхшырак булыр иде. Аларны татулаштыру юлларын әле судка кадәр үк эзләргә һәм мондый шартны мәҗбүри итү фикере дә әйтелде очрашуда.

Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, хәзерге заман судьясы профессионал, тәртип һәм гаделлек мәсьәләсендә үзе үрнәк күрсәтергә, законны үтәргә, югары хокукый культурага ия булырга тиеш. «Мондый судьяга кеше ышанычак, – диде ул. – Ул судның абруен күтәрүгә дә ярдәм итәчәк».

НАЧАР ТҮГЕЛ. БҮГЕНГӘ

Дәүләт Советында бюджет турындагы закон проекты буенча фикер алышулар дәвам итә. 2023 ел ьәм 2024–2025 еллар план чоры бюджеты турындагы закон проекты беренче укылышка әзерләнде ьәм тиздән булачак парламент утырышында каралачак.

– Хәзерге вазгыять гади түгел, бүген республика икътисадка янаган куенлыкларны киметергә тырыша, логистик элемтәләрне көйли, – диде журналистларга Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс буенча комитеты рәисе Леонид Якунин.

Республиканың финанс министры Радик Гайзатуллин билгеләп узганча, Татарстанның берләштерелгән бюджетына быелның 9 аенда салым һәм салым булмаган керемнәр 310 млрд сум күләмендә тупланган. Иң эре керем чыганагы – табышка салым, аның күләме 134,4 млрд сумны тәшкил итә. Физик затларның керемнәрә салым да дәүләт казнасын 76 млрд сумга баеткан.

– 2022 ел бүгенгә начар түгел, гомумән алганда 9 ай күрсәткечләре һәм фаразлар барлык бурычларны да үтәп чыгарга мөмкинлек бирә, – диде министр.

Радик Гайзатуллин сүзләре буенча, республиканың төп салымнары федераль бюджетка керә. Болар – нефтьчеләр түли торган файдалы казылмалар өчен һәм өстәмә бәягә (ндс) салымнар.

– Бүген аларның суммалары һәм процентлары да зур. Узган ел, мәсәлән, Татарстанда салым һәм салым булмаган керемнәр 1 трлн 100 млрд сум тәшкил иткән булса, шуның 70 проценты федераль бюджетка китте. Моннан тыш, безнең әле таможня салымы һәм фондларга күчерә торган акча бар. Алар тулысы белән Россия бюджетына күчереләләр, – диде ул.

Радик Гайзатуллин әйтүенчә, федераль законнардагы үзгәрешләр бюджетның керем өлешенә тискәре йогынты ясый.

– Әлеге вакытта 17 яшькә хәтле баласы булган гаиләләргә түләүләр һәм йөкле хатыннарга түләүләрнең кайберсе 100 процент федераль бюджеттан түләнә. Киләсе елга бердәм система кертелсә, 60 процентын Россия бирәчәк, 40 процентын республика күтәрергә тиеш була. Бу закон кабул ителгән очракта, Татарстан бюджетына өстәмә авырлык килү ихтималы бар. Әлегә бу – безнең өчен яңалык. Икенчесе нефть эшкәртүчеләргә кагыла. Алар өчен пошлина күләме быел сентябрьдән декабрьгә кадәр арткан иде. Аны 2023–2024 елларга тагын арттыруны карыйлар. Ул яңадан безнең салым керемен киметергә мөмкин. Шуңа күрә без сезнең белән бик киеренке чорда яшибез. Бүген федераль бюджетка да җиңел булмавын аңлыйм, шул ук вакытта республикага моны формалаштыру һәм киләсе елда тормышка ашыру җиңел булмаячак, – диде ул.

Моннан тыш, Радик Гайзатуллин бюджет оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хаклары киләсе елның 1 гыйнварыннан 10 процентка артачагын белдерде.

Бюджетның авыр шартларда каралуына Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов та басым ясады.

– Бюджет бер дә гади түгел, ләкин анда барлык социаль гарантияләр исәпкә алынган, – дип бәя бирде ул илнең төп финанс законына. – Шул ук вакытта түләүләрне, пособие һәм пенсияләрне индексацияләү генә түгел, төрле сәбәпләр аркасында моңа кадәр җитәрлек күләмдә финансланмаган тармакларга да игътибар булачак.

Ул 1 гыйнвардан пенсияләр 4,8 процентка артуын әйтте. Моннан тыш, Россия хөкүмәтенең социаль ярдәмне арттыру буенча тәкъдимне карауны дәвам итүен белдерде.

– Инде киләсе атнада без кешеләр өчен административ барьерны киметергә ярдәм итүче яңа төр пособиеләр буенча фикер алышачакбыз. Монда сүз бала туганнан алып 18 яшькә җиткәнче бирелә торган «универсаль пособиеләр», йөклелек буенча хатын-кызлар консультациясенә иртәрәк учетка баскан өчен бирелә торган пособиеләр һәм башкалар турында сүз бара. Әлеге барлык финанс ресурслары Пенсия фондында берләштереләчәк.

Әлбәттә инде, журналистлар дөнья вакыйгаларының икътисадка булган йогынтысы турында да сорамыйча калмады. Бу уңайдан Айрат Фәррахов Россия бюджеты проектының кайбер валюталар белән исәпләүне игътибарга алмавын әйтте.

– Бүген доллар һәм евро – дус булмаган валюталар. Без аларга таяна һәм алар белән исәпли алмыйбыз, шул исәптән төп финанс документын да. Чөнки әлеге валюталар безнең кулда түгел. Бүген Россия Хөкүмәте һәм Дәүләт Думасы сумны ныгыту турында уйлый. Без аның ни дәрәҗәдә ныгуын күрәбез. Һәм без алыш-бирешләрнең сумнарда яки дустанә валюталарда булуы өчен тырышабыз, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Чаллы шәһәр суды судьясы **Гайфетдинов** Ринат Галләметдин улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Ибраһимов һәм К» авыл хуҗалыгы предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Апас районы) **Ибраһимов** Таһир Кәбир улы, «Шәмәрдән ашлык кабул итү предприятиесе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (Татарстан Республикасының Саба районы) **Вәлиев** Фәнис Таһир улы, «Берсут» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (Татарстан Республикасының Мамадыш районы) **Кириллов** Николай Петрович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык намуслы хезмәтләре, актив иҗтимагый эшчәнлекләре һәм республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүгә өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасының Ветераннар советы әгъзасы **Гайфуллин** Рафис Гайфулла улы, Татарстан Республикасы ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы, Казан шәһәренең күпфатирлы йортлар советы – йорт комитетлары берлеге рәисе **Сомов** Геннадий Михайлович, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы советының мәдәни-массакүләм чаралар комиссиясе рәисе **Старшинина** Лидия Рәхим кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятенең махсус продукция производствосында станоклар һәм слесарьлык эшләре контролеры **Вилкова** Розана Габдерәхим кызына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татагромодуль» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Гарәфиев** Рәшит Сәлахетдин улына, «СтройИнжиниринг» инвестиция төзелеш корпорациясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының төзелеш буенча урынбасары **Лопухов** Алексей Петровичка, «Тукай муниципаль районының капиталь төзелеш хезмәте» муниципаль унитар предприятиесе директоры **Сәетгәрәев** Фәнис Мизхәт улына, «Домкор Строй» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры (Чаллы шәһәре) **Тряев** Николай Владимировичка, «ТАТЭЛЕКТРОМОНТАЖ» акционерлык җәмгыятенең проектлау идарәсе башлыгы **Халтурин** Владимир Александровичка, «ПРОСТОР-С» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Шәмсетдинов** Айрат Хәләфетдин улына, «ЮЛ СЕРВИСЫ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары (Татарстан Республикасының Арча районы) **Котдусов** Хәбир Галимҗан улына; «Алексеевскдорстрой» ачык акционерлык җәмгыятенең экскаватор машинисты (Татарстан Республикасының Алексеевск районы) **Степанов** Михаил Ивановичка **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Әйтеп кенә бактым

Тыл

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Әлфинурны күптән күргән юк иде. Яшьрәк вакытта эш буенча шактый аралаштык. Район мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе иде ул. Телевидение өчен тапшырулар әзерләгәндә, гел шуның янына керә идем. Мәгълүм сәбәпләр аркасында, кайсы районныкы икәнен әйтеп тормыйм, үпкәләве бар.

Җыйнак кына гәүдәле курчак кебек кыз иде Әлфинур. Еллар гәүдәсенә дә, үз-үзен тотышына да үз эзләрен салган. Командировкага баргач, очраклы гына очраштык. Башта танымыйчарак тордым. Исемем белән дәшмәсә, янымнан узып киткән булыр идем. Күзләре бик моңлы иде Әлфинурның. Нәфис куллары да шактый тупасланган. Хәлләрен сораша башлагач, елмайгандай итә, әмма барып чыкмый. Сөйләшә торгач, бераз ачылып китте тагын һәм бер тында дигәндәй, бөтен хәлен сөйләп бирде.

Кияүгә чыгып, бер-бер артлы ике бала таба Әлфинур. Берничә ел узгач, моның ире гаиләсен ташлап чыгып китә, яшь хатын белән яши башлый. Берүзе балаларын аякка бастыра Әлфинур. Укыта, кем әйтмешли, кеше итә. Һәм беркөнне, көтмәгәндә-уйламаганда, моның ире кайтып керә. Элекке кебек көттә «любвиобильный» егет түгел инде. Аякларын да сөйрәп кенә йөри. Ни гаҗәп, Әлфинур моны кабул итә. «Бик жәлләдем, Риман абый. Ни дисәң дә, балаларның әтисе бит», – диде. Шул ук вакытта күңелендә рәнҗү, үпкә хисләре саклануын да яшермәде. Бу вакыйга турында таныш һәм таныш булмаган хатын-кызларга да сөйләдем. «Әлфинур урынында сез булсагыз, нәрсә эшләр идегез?» – дидем. Араларында: «Бусагадан ук борып җибәрер идем», – диючеләр дә булды. Әмма алар бик аз иде. Яши-яши шаккатам мин гүзәл затларга. Ирләрне көчле затка санау бик үк дөрес түгел икән, дип тә уйлана башладым.

Безнең татарда «Ирне ир иткән дә, чир иткән дә – хатын» дигән әйтем бар. Аны бабаң түгел, заман чыгарган.

Тормышта хатын-кызның урыны турында ирләргә дә сүз катканым булды. Барысы да диярлек, хәтта югары дәрәҗәләргә ирешкән шәхесләр дә: «Тыл нык булмаса, ир кеше үзе генә әллә ни майтара алмый», – диләр.

Сугыш вакытында тылда эшләгән хатын-кызлар турында да уйланам. Илгә җиңү ялуауда нәкъ менә аларның өлеше дә бик зур бит! Сугыш турында күпме китаплар язылды, күпме фильмнар төшерелде, ә тыл, ягъни икенче фронт батырларын бәяләп бетермәдек кебек.

Яңадан Әлфинур турында уйланам әле. Алар үз йортларында яшиләр икән. Ирен бәдрәфкә дә күтәреп диярлек алып чыгуын сөйләде. «Кулсыз калам бугай инде», – дип моңсуланып куйды, әмма ире турында бернинди яман сүз дә әйтмәде. «Үзен бик яраткансыңдыр, бәлки, кайтыр әле, дип көткәнсеңдер», – дип тә карыйм. «Мәхәббәтебез көчле иде. Һәрхәлдә бу хисне үзем Ходай Тәгаләнең бүләге дип кабул итеп яшәдем. Әмма еллар узып, бу хис сүрелде һәм бүтән кабынмас инде», – ди Әлфинур. Үзе исә ирен бала карагандай карый.

Шаккатам мин бу көчле затларга. Мин хатын-кыз күрмәгән кеше түгел, дөресен әйтим. Әмма алар бүген дә ачылып бетмәгән китап кебек. Алардагы көчкодрәт, түземлек, сабырлык бездә юк. Ялгыз калган ир озак яши дә алмый әле.

Инде менә ничә еллар статистиканы күзәтеп килим: Җир йөзенә ни өчендер хатын-кызлар күбрәк туа. Бу очраклы хәл түгелдер. Аллаһы Тәгалә, бәлки, Җирдә яшәү тукталмасын дип, хатын-кызларны ишлерәк иткәндер, дип тә уйлап куям. Монысы – аптырагаиннан әйтү инде. Минем өчен хатын-кыз үзе дә – илаһи зат. Башка «көчле» затлар ничек уйлыйдыр тагын...

Шушы юлларны яздым да, өйгә кайтып, үзем өчен ныклы тыл булган хатынымны кочаклап алып, тагын бер кат пәп итәсе килеп китте.

БИШЕНЧЕ СТАТЬЯ ТИРӘСЕНДӘ БИЮ

Соңгы көннәрдә Россия катнашында зур глобаль конфликт төенләнә һәм ул безгә, җай гына тормыш итеп ятарга күнеккән гади кешеләргә, зур куркыныч тудыра. Күптән уйланылган һәм алдан планлаштырылган сценарий уйнала һәм вакыйгалар бик кызу бөтерелә. Белем: газета укучыларның байтагы авторны юләргә санар, редактор язманы архивка ташлап котылырга теләр, бәлки, ул басылмас та. Автор дәлил итеп бары тик рәсми хәбәрләрне генә китерә һәм уяу булырга, уйланырга чакыра.

Әйдәгез, БМО Генераль Ассамблеясында Россия вәкиле Небензяның чыгышыннан өзек китерик әле: «НАТО күптән инде Россияне җиңү һәм хәлсезләндерү планнары йөртә һәм бу максат өчен Украинаны сайлады», – диде ул. Моңа «Российская газета» сайтыннан алып, Тышкы эшләр министрлыгы белдерүен өстик: «АКШның Украинада тынычлык урнаштыруга ялган өндәүләре артында... Россияне стратегик тар-мар итүдән башка берни дә ятмый». Россия дипломатиясе хәлне куерта, күпертә дип санасак, Казахстан Президентын тыңлап карыйк. «... Ап-ачык: хәзерге дөнья тәртибе куәтле кризис кичерә һәм аның нәтиҗәләре барлык илләр өчен дә фаталь булырга мөмкин».

Чаң сугучы сәясәтчеләрнең һәм лидерларның тулы бер исемлеген китерә алам мин. Һәм алар барысы да соңгы атнада ыгы-зыгы куптара, чөнки беләләр: вазгыять җитди төс ала. «Вашингтон пост»ка сүз бирик (ул – Американың иң йогынтылы газеталарыннан берсе): «Украинада сугыш (алар махсус хәрби операция дип атамыйлар. – **Р.Ф.**) конфликтның тиз кискенләшүе белән бәйле борылыш этабында...» Fox Newsта – штаб-квартирасы Нью-Йоркта урнашкан мәгълүмат телеканалында – Америка штаб начальникларының Берләштерелгән комитеты (бездәге Генштаб кебек) элекке җитәкчесе Джек Кинның туры эфирдагы чыгышына игътибар итик. Ул АКШның Украинаны үз максатларына ирешү өчен файдалануы турында яшереп тормыйча сөйли. 24 февраль алдыннан һәм аннан соң да Америка сәясәтчеләре һәм хәрбиләре бу максатларын яшерәләр иде әле. Хәзер мәгълүмат кырында алар тантана итә.

Россия бу янауларга ничек җавап бирергә җыена? Тышкы эшләр министры урынбасары Сергей Рябков әфәнденең рәсми белдерүен карыйк: «АКШ һәм аның Европадагы союзникларының Украинадагы конфликтка үсә баручы тыкшынулары шуңа китерә: Россия аларга җавап бирергә һәм контрчараларга барырга (шул исәптән ассиметрик чараларга да) мәҗбүр була», – диде ул 11 октябрьдә. Менә бу «ассиметрик» чаралар дигәне бик борчый мине. Сүз бит күпләп юк итү коралы, асылда тактик атом-төш бомбаларын куллану турында бара. Әйе, Россия җитәкчелеге һәм дипломатиясе аларны телгә алганда куркытырга һәм каршы якны чигендерергә генә тели. Әмма каршы як чигенми генә түгел, Мәскәүне куркыныч адымга этәрү бурычын тактик максат итеп куйды.

Үзара янауларны читкә куеп, конфликтның асыл сәбәбен ачыклап карыйк әле. Сүзне Америка спекулянты, чыгышы белән япон, байлык туплау ысуллары турында популяр китаплар авторы Роберт Кийосакига бирик: «Менә башланды да... Гомуми куык гомуми җимерелүгә әйләнә. Бу тарихтагы иң бөек җимерелү булачак». Кийосаки, тарихта күрелмәгәнчә, байлыкларны яңадан бүлү башланачак дип фаразлый. Белдерү октябрь башында ясалды. Чәршәмбе иртәсенең глобаль базарлардан алынган иң яңа хәбәрләре мәшһүр спекулянтның хаклы булуын дәлилли. «Форбс» журналы иң тиз үсүче инвесткомпания дип бәяләгән хатын-кыз инвестор Кэти Вудның ARK Investment фондының акцияләре 4 тапкыр арзанайды. Сүзнең җилгә очкан миллиардлар турында баруын аңлыйсыздыр. Tiger Global дип аталган иң атаклы венчур фонды инвесторлары акчасының 66 процентын югалтты. Кэти Вуд ФРСтан ставканы күтәрүдән туктауны инәлеп сорый. Аны кем тыңлый соң! Фонд базарын тизләтелгән темпта җимерү максат итеп куелды. Төп ставканы күтәрмәсәң дә, базарлар барыбер бөләчәк иде, әмма бераз соңрак. Дөнья байлыкларын үз кулында тотучы иң эре банкирлар вакыйгаларны бераз ашыктырырга булдылар, бары шул гына. Кытай фондлары – даими җимерелү стадиясендә, иң ышанычлы дип саналган Швейцария банклары ут төртелгән шырпы кабы кебек яналар. Credit Suisse банкы көн саен кыйммәтен югалта, кертем ияләре аннан акчаларын чыгарып саклап калырга телиләр. Инвесторлары, банкны судка биреп, үз малларын тартып алмакчы булып мәшәкатьләнә. Credit Suisseга акча салган россиялеләр исә тын гына сызалар, чөнки санкцияләр астында булганлыктан, хокуклары юк. Акчаларының тиенен дә ала алмаячаклар, димәк.

Менә бу базар түнтәрелешләре, инвесторларның миллиардлардан колак кагулары, энергетик кризис (шулай ук махсус китерелеп чыгарылган матавык), Кийосаки теле белән әйтсәк, тарихтагы иң бөек җимерелү, кешелек тарихындагы иң бөек конфликтны китереп чыгара да инде. Кызганыч, аның увертюрасы Россиянең турыдан-туры катнашында уйнала. Көнбатышта Россияне бу хәлләрнең сәбәпчесе итеп күрсәтергә һәм җәзага тартырга ниятлиләр. НАТОның оборона министрлары утырышы алдыннан оешманың генераль секретаре Йенс Столтенберг матбугат вәкилләренә менә нинди белдерүләр ясады: «Россиянең җиңүе НАТОның җиңелүе булачак, моңа юл куярга ярамый. НАТОның оборона министрлары Украинага ярдәмне көчәйтәчәк. НАТО корал запасларын арттыру һәм критик инфраструктураны саклау чаралары турында карар кабул итәчәк. НАТО илләренең инфраструктурасына гибрид һәм киберһөҗүмнәр альянсның коллектив оборона турындагы килешүенең 5 нче статьясын активлаштыруга сәбәп булырга мөмкин. НАТО «Төньяк агым»нардагы диверсияне тикшерүнең нәтиҗәләрен көтә».

«Татар-информ»

Соңгы җөмләгә игътибар итик. Көнбатышта торбаларны Россия шартлатты дип баралар. Мәскәү АКШ диверсиясе дигән фаразны алга сөрә. «Лондон ашыгыч рәвештә, Россиянең аларга һөҗүме әзерләнүдән куркып, су астындагы кабельләрне һәм торбаларны тикшерергә кушты. Хакимиятләр барыннан да бигрәк су астындагы «Лангелед» торбаўткәргече өчен борчылалар. Бөекбританиягә Норвегиядән газ шуның аша килә», – дигән хәбәр укыйбыз яңалыклар тасмасыннан. Күрәбез, тикшерү төгәлләнмәүгә карап тормыйча, һөҗүм итүче көчне Россия дип билгеләп куйганнар инде.

Соңгы көннәрдә генә кемнәрнеңдер кабельләрне өзүе сәбәпле, Германиядә поездлар туктады. Шул ук сәбәп белән ут өзелгән илләр булды. Нининдер бер кара көч 5 нче статьяны кулланырга сылтау әзерли бит монда. НАТО килешүенең 5 нче статьясы ул альянска һөҗүм ясаучыга күмәк һөҗүм белән җавап кайтаруны күз алдында тота. НАТО – Россия кораллы конфликтын оештырырга тырышу ярылып ята.

Соңгы атналарда Украина конфликты белән бәйле рәвештә сәяси шахмат тактасында төп йөрешне Согуд Корольлеге һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре ясый башлады. Борларның агымдагы вазгыятьтә йогынтысы зур. Россия олигархларының исән калган активлары Дубайда саклана, нефть бәясенә төп тәэсирне дә шул ике дәүләт ясый. БГӘ Президенты Петербургта Владимир Путин белән очрашуга украин кризисын хәл итүдә арадашчы буларак килде. Бу хакта әмирлекләрнең WAM агентлыгы хәбәр итә. Мәскәүне компромисска өндиләр. Төрек башлыгы Әрдоган да Көнбатыш лидерлары белән Путинны бер өстәл янына утыртырга омтыла. Төрекләр өчен Кара диңгездә зур һәлакәтнең һич тә кирәге юк. Мөселман илләре лидерлары белән яхшы мөнәсәбәтләрне саклау Россия өчен зур әһәмияткә ия. Әгәр ул мөнәсәбәтләр бозылса, кыен хәлдә калачакбыз.

Язма авторы киләчәккә оптимистик фараз бирә. Әйе, зур давыл узарга ихтимал безнең өстән, әмма без, ин шәә Аллаһ, исән калачакбыз. Аннан соң киеренкелек бөтенләй башка мәйданга күчәр. Менә ул мәйданда инде фаҗига зуррак масштабта уйналачак. Әмма анысының да ахыры хәерле булыр, Аллаһ теләсә.

P. S. Бу юллар язылганда, «Дружба» нефть үткәргече дә тишелде бит әле анда. Анысын да диверсия дип санаучылар бар.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

МЫЛТЫК ҺӘМ ТУГРЫЛЫК


«Татар-информ» / Михаил Захаров

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Тәҗрибәнең артыгы юк

Казанга Лаеш ягыннан керүчеләрнең күбесе зур юлдан ерак түгел урнашкан полигонда ниләр булып ятканын күз алдына да китерә алмый. Бирегә рөхсәтсез керү мөмкин түгел. Ә сак пунктын узып, берничә йөз метр баруга, танклар чабышканы, кораллы кешеләр йөгерешкәне күренә. Күнегүләр полигоны берничә өлешкә бүленгән. Егетләрне төрле кораллардан атарга, танкка каршы торырга, шартлаткычлардан сакланырга, окоп казырга, медицина ярдәме күрсәтергә өйрәтәләр. Күнекмәләр тәҗрибәле хәрби белгечләр һәм «кайнар нокта»ларда булып кайткан сугышчылар кулы астында уза. Кемнәр икәнен әйтеп бетермиләр. Иртәдән кичкә кадәр шулай. Вакытны бушка уздырырга ярамый. Бирегә өйрәнгәннәр, ахыр чиктә, үз гомереңне саклау өчен дә кирәк булачак. Тәҗрибәнең артыгы юк.

Инструктор, тормышта төрлесен күргән Рөстәм дә шулай ди. «Әйтик, менә бу төркемдәге егетләрнең сугыш хәрәкәтендә катнашу тәҗрибәләре бар. Берәүләр – Чечняда, икенчеләре үз теләге белән Донбасста булып кайткан. Төньяк Кавказ белән Украинадагы хәлләр нык аерыла. Бирегә, нигездә, артиллерия кулланыла. Диверсия-разведка төркемнәренең чит ил инструкторлары кул астында яхшы әзерлек узганы күренеп тора. Безгә каршы ялланган кешеләр армиясе сугыша. Инглизләр, поляклар күп, грузиннар очрый. Русча сөйләшүчеләр дә бар. Алары – террорчылар ягына күчкән сатлыкҗаннар инде», – ди әле август аенда гына махсус хәрби операция зонасыннан кайткан ветеран.

«Читтә кала алмадык»

Өлешчә мобилизация аңа кагылмаган, әмма ул үз теләге белән тәҗрибә уртаклашырга килгән. «Махсус операциягә үз теләгем белән чыгып киттем. Яшь егетләр һәлак булганда, читтә кала алмадык. Ватанны саклау – безнең бурычыбыз, тәҗрибә дә бар. Андагы фашизмны, нацизм ялчыларының ни кыланганын күрдек. Тыныч халык белән аралаштык. 8 ел эчендә ни генә күрмәгән алар! 35 яшьлек хатын-кызлар 70 яшьлек кыяфәткә кергән. Аларны күргәч, ничек битараф каласың?! Бу фашизмны юкка чыгарырга кирәк», – ди ул һәм бу атнада Украина ягына ракеталар очуга сөенгәнен яшерми: күптән кирәк иде.

Буа егете Ринатның да Донбасс якларында булганы бар. Тыныч тормышка кайткач, сак хезмәтендә эшләгән, хәзер ул – взвод командиры урынбасары.

– Куркып калган егетләр дә бар. Аларга киңәшләр бирәбез. Юкса үзләренә дә, туганнарына да авыр булачак. Повестка килгәч, үзем уйлап та тормадым, ә өйдәгеләр төн буе елады. Аннары тынычландылар. 2 нче сыйныфта укучы улыма командировкада дип әйттеләр. Сөйләшеп торабыз, әмма монда алып килмәскә куштым. Рәхмәт, безне онытмыйлар. Әле менә Буа районыннан күчтәнәчләр алып килделәр, – ди ул. – Барысы да бар. Кемдер, акча өчен йөриләр, ди, ләкин мин бирегә аның өчен килмәдем. Ватанны сакларга кирәк. Егетләр моны аңлый. Барысы да китәргә әзер. Әлегә корал тотарга гына түгел, бер-беребезгә ярдәм итәргә дә өйрәнәбез. Тегендә баргач, янәшәңдә кем булуын белеп торырга кирәк.

Егетләр яшерми: берничә көн эчендә армиядә күрмәгәнне дә өйрәнергә өлгергәннәр. Чүпрәледән Андрей хәрби хезмәттән 5 ел элек кайткан. Сигнализация урнаштырырга ияләшкән куллары хәзер пулемет тотарга өйрәнә. Инструкторы мактады үзен. Әмма камиллекнең чиге булмый. «Сугышлы уены»нда каршы яктан атучы юк, ә тегендә барып эләккәч…

Казан ипподромында эшләп, ат чаптырган Маратның, безнең белән очрашканда, граната атарга әзерләнеп ятышы иде. Сүз уңаеннан, егетләргә өйрәнчек коралдан соң чыны белән дә күнегүләр уздырырга туры киләчәк.

– Чабыш сезоны бетүгә, повестка килеп төште. 28 сентябрьдә. Шулай буласын сиздем, качып йөрү уема да кермәде. Яшермим, башта курку да, борчылу да булды, аннары тынычландым инде. Әлегә көн-төн диярлек шунда ятабыз. Кая кем булып барасымны белмим. Армиядә күрмәгәнне өйрәтәләр, – ди хәрби хезмәттән моннан 14 ел элек кайткан ир-егет. – Монда бер гаилә булырга кирәк. Бер-беребезне кайгыртырга, баш белән эшләргә өйрәнәбез. Әмма дәүләт тә безнең турында онытмасын, бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итсен иде. Ә без илне сакларбыз.

«Егетләр, бергә булыйк!»

Баш белән эшләү димәктән, күпне күргән хәрбиләр егетләргә гади генә тормыш киңәшләре дә бирә. Тәмәкенең кирәге юк, хәмер белән дә шаярасы түгел: сугыш кырында аракы батырлыкка түгел, бакыйлыкка илтә. Телефоннан да чамасын белеп файдаланасы. Якыннарыңа сәлам сүзе әйтеп өлгергәнче, дошман ягыннан снаряд килеп төшәргә мөмкин.

Буадан Таһирның спецназда хезмәт итү тәҗрибәсе бар. Армиядән кайтып, 10 ел дәвамында транспорт оешмасында эшләсә дә, бу кагыйдәләрне онытмаган ул.

– Авыр урыннарда хезмәт иттем. Әмма Ватанны сакларга кирәк. Безнең ротадан гына да иллеләп егет үз теләгебез белән чыгып киттек. Бернинди курку юк. Егетләр барысы да үз бурычын үтәргә риза. Бер-беребезне кардәшләр дип йөртәбез. Барыбыз бергә зур бер гаилә кебек, – ди ул. – Өйдәгеләргә сәлам, ярдәм итүчеләргә рәхмәт. Монда барыбыз да – гади авыл малайлары. Шәһәрнекеләр дә бар, әлбәттә. Ашаталар, киендерәләр, йоклаталар – барысы да әйбәт. Егетләр, безгә кушылыгыз! Чибәр кызларны, әти-әниләрне, хатыннарны, туганнарны саклыйк!

Илнар ХӘСНУЛЛИН

Сүзгә-сүз

Дмитрий ПЕСКОВ, Россия Президентының матбугат секретаре:
– Мобилизациянең бернинди дә яңа дулкыны юк. Губернаторлар әйткән икән, нәрсәне күздә тотуын үзләреннән аерым ачыкларга кирәк. Өлешчә мобилизация барышында система эшендәге хаталар һәм җитешсезлекләрне белгечләр генә түгел, барысы да күреп алды. Бу хаталар табылмаса, проблемаларның барлыгы да ачыкланмас иде. Ә хәзер бу системаны тәртипкә китерү буенча чаралар күреләчәк.

Көрәшче Нәсим ГАБИДУЛЛИН:

«ЧАКЫРУНЫ КАПКА ТӨБЕНӘ ҮК КИТЕРДЕЛӘР»

Арча районының Иске Масра авылы батыры Нәсим Габидуллин (*рәсемдә сулдан беренче*) **хәзерге вакытта Казан читендәге танк полигонында хәрби өйрәнү уза. Көрәш буенча Россиянең спорт остасы өлешчә мобилизациягә әлегә турында 24 сентябрь көнне белгән.**

– Чакыру кәгазен капка төбенә үк китереп бирделәр. Дөресен генә әйткәндә, чакырасыларын белдем, моңа әзер идем. Якыннарым бик сөенмәде, әлбәттә, борчылдылар. Көн саен аралашып торам үзләре белән, – дип сөйләде безгә 23 яшьлек егет.

Нәсимне армиягә Арча педагогика көллиятен тәмамлауга, 19 яшендә алалар. Сүз уңаеннан, белгечлеге буенча ул – музыка укытучысы.

– Хәрби хезмәтне Саратовта, РХБЗ гаскәрләрендә уздым. Армиядән 2019 елда кайттым. Кайткач та тозелештә эшләдем, – ди ул.

Нәсим Габидуллин – яшьләр арасында Татарстан һәм Россия чемпионы булып танылган егет. Илкүләм ярышларда җиңү яулады. Үзе Казанда эшләп йөрсә дә, һәрвакыт Арча районы командасында чыгыш ясады. Хәзер ул Казан читендәге полигонда хәрби өйрәнү уза. Башка егетләр белән уртак телне тиз тапкан.

– Арчадан киткәндә, башта курку бар иде, билгеле. Хәзер тынычландым инде. Мин берүзем түгел бит. Әлегә өйрәнү дәвам итә. Атабыз, йөгерәбез. Көрәшче булуымның да файдасы бар, – ди 90 кило авырлыкта бил алышкан батыр.

Өлешчә мобилизациягә эләккән егетләрнең әти-әниләренә, якыннарына Нәсимнән бары бер теләк:

– Юкка-барга борчылмагыз! Теләп торыгыз. Алла боерган булса, бар да яхшы булачак.

Ачыклау

Татарстанда хәрби кафедра тәмамлаучыларны өлешчә мобилизация буенча чакырачаклар. Мобилизация башлангач, алар алган белгечлекләргә ихтыяҗ барлыгы ачыкланган. Бу хакта «Татар-информ»га Татарстан Хәрби комиссариатында әйткәннәр. Мондый карар озакламый илнең башка төбәкләрендә дә кабул ителергә мөмкин. Татарстан хәрби комиссариатында әйтүләренчә, хәлиткеч карарны чакырылыш комиссиясе кабул итәчәк. Аларны чакыруны кичектереп тә торырга мөмкиннәр. «Рядовойларның гомерен саклап калу һәм хәрби бурычларны уңышлы үтәү өчен акыллы командирлар кирәк. Өлешчә мобилизация планына үзгәрешләр кертүнең сәбәбе әнә шуңа да бәйле», – диелә агентлык хәбәрендә.

ЯШӘТӘСЕ ИДЕ!

ИСЛӘЙ ХАЛКЫН НӘРСӘ БОРЧЫЙ?

Зөлфия Хәлиуллина

Чистай районының Исләй авылында халык күпләп терлек асрый, кош-корт тота, умартачылык, бакчачылык белән шөгыльләнә. Тик халыкны авылның бетүе, аралаша торган урын – мәдәният йортының бик начар хәлдә булуы борчый.

Исләй авылы – Чистай районының гына түгел, Татарстанның да иң борынгы авылларының берсе. Аның 700 еллап тарихы бар. Бүген биредә 82 хуҗалык исәпләнә. Шуларда 152 кеше теркәлгән, яшәүчеләр тагын да азрак. Кибете, мәктәбе, фермасы юк. Аның каравы матур гына, җыйнак кына мәчете бар. Мәдәният йорты, китапханә, фельдшер-акушерлык пункты да бар. Тик бинасы гына бик иске. Без, журналистлар, төрле районнарда күп йөргән кешеләр буларак, мондый бинаны күргәч, бик гаҗәпләндек. Дүрт оешма (җирле үзидарә дә шушы бинада утыра. – **Авт.**) урнашкан бина 1972 елда төзелгән һәм шуннан бирле бер тапкыр да ремонт күрмәгән. Дөресрәге, аларның һәркайсына берәр бүлмә бүлеп бирелгән. Алар иске, шыксыз гына түгел, без барганда бик нык салкын да иде. Әллә урамда салкын җил, яңгыр сибәләп торганга, бина безгә тагын да шыксызрак булып күренде. «Бу яктан бер начар сүзебез дә юк, – диде авыл халкы. – Башка елларны бик җылы була иде бүлмәләр. Әлеге вакытта котельныйны ремонтлыйлар, казаны искергән иде. Бүлмәләрнең суык булуы шуңа гына бәйле. Киләсе атнада җылы җибәрәчәкләр».

«Без яшәгәндә, авыл яши әле»

Халыкны җыйнап, туплап тора торган бинаның шундый хәлдә булуына гаҗәпләнсәк, халыкның тырышлыгына ихластан сокландык. Бирედә яшәүче һәр гаилә диярлек күпләп терлек асрый, сөт эшкәртеп сата, кимендә 50шәр баш үрдәк һәм каз, тавык асрыйлар, умартачылык белән шөгыльләнәләр. Өч фермер бар. Шушы зур булмаган авылда 320 мөгезле эре терлек бар. Шуларның 85е – савым сыеры.

– Авылыбыз, башка бик күп авыллар кебек үк, сүнеп бара. Ләкин без булдыра алганча аны бетермәскә, яшәтергә тырышабыз, – дип көн итә биредә халык.

Әйтик, фермер Гөлкәй Нуретдинова ун-унбиш ел элек 15 үгез, 100 баш каз асрый башлаган.

– Тиздән каз өмәләре җитә. 10–15 хатын-кызның кызу эш чоры башлану дигәнне аңлата инде бу. Бер-беребезгә ярдәм итешеп яшибез, хезмәтеннән дә иренмибез, безгә ул – аралашырга бер форсат кына. Кош-корт асрауның табышы бар, әлбәттә. Казның керемен тизрәк аласың, 5 айда өлгерә бит ул. Үгезне исә 1,5 ел асрарга кирәк, – диде ул.

– Бездә һәр йорт хуҗасы күпләп терлек асрый, – дип сүзгә кушылды китапханәче Зөлфия Фәтхетдинова. – 15 баш үгез янында 6шар сыер асрау – безнең халык өчен гадәти күренеш. Сөтне 28 сум 50 тиеннән килеп җыялар. Мин үзем – ялгыз хатын. Шулай да ике сыер савам, казлар, үрдәкләр асрыйм, дүрт бозавым бар.

Тагын бер фермер Кадрия Чернышева яшелчәчелек белән шөгыльләнә. 2019 елда грант отып, кишер, чөгендер, кәбестә үстерә башлаган ул. Моннан тыш, 30 сутый җиргә виктория җиләге утырткан.

– Мин бухгалтер-икътисадчы идем. Хуҗалык таркалгач, эшсез калдым. Шуннан соң кибеттә эшли башладым, анысын да яптылар. Шулай итеп, авыл хуҗалыгына килдем. Җиләкне үзебез өчен дип кенә утырткан идем, халык сорап килгәч, җиләген дә, үсентеләрен дә саткалыйм. Башка яшелчәләрне табыш алырга дип махсус үстерәм. Акрын гына техникалар да алдым. Табышы юк түгел инде. Төп ярдәмчем – ирем. Җаен теләге булганнарга эш урыннары да тәкъдим итәм, – диде Кадрия ханым.

Тагын бер бик тә тырыш гаиләгә – Дания һәм Рамил Әхмәтҗановларга кердек. Газетабызның киләсе саннарында алар турында тагын язарбыз әле. Алар да күпләп казлар, үрдәкләр, үгезләр үстерә, умарта тоталар, бакчачылык белән шөгыльләнәләр. Дания ханым 43 ел мәктәптә эшләгән. Шуның 38 елы – мәктәп директоры вазыйфасында. Алты ел элек үз авылларындагы мәктәпне башлангычка гына калдыргач, Чистайның 6 нчы мәктәбен җитәкләгән. Быел исә эшеннән туктарга булган.

– Мәктәбебез бик кызганыч. Бинасын бик нык караган идек. Шуның әрәм булып ятуына күңелем әрни. Аның бинасы да, территориясе дә матур. Картлар йорты яки башка социаль учреждение ясасалар, бик яхшы булыр иде югыйсә. Менә шушы мәдәният йортын, китапханәне, авыл советын һәм фельдшер-акушерлык пунктын шунда күчерегез, дип, район башлыгы Дмитрий Иванов янына да кердем. Тик ни сәбәпледер алай эшләмәделәр, – диде Дания Әхмәтҗанова.

Клуб мөдире Гөлнур Фәтхетдинова – өч бала әнисе. Кечкенә кызларына нибары 4 ай гына. Нарасые булуга карамастан, ул инде эшкә дә чыккан.

– Без каенанам һәм каенатам белән яшибез. Күп итеп маллар асрыйбыз. Алты сыерыбыз, унбишләп үгезебез бар. Мин күбрәк балалар карау, тәрбияләү, өйдәге эшләр белән мәшгуль булсам, терлекләр – ирем җаваплылыгында. Шулай ук каенанам белән каенатам да аңа ярдәм итә. Моннан тыш, ир-атлар тракторда эшли. Элегрәк әни сөтне эшкәртеп, каймак, эремчек ясап сата иде. Кызым тугач, мәшәкать тә артты. Шуңа күрә хәзер сөтне тапшыра гына, – диде ул.

Гөлнур әйтүенчә, авыл кечкенә, яшьләр аз булса да, апалар бик актив.

– Бер бәйрәмне дә калдырмыйча концертлар куябыз. Клубта хатын-кызлар кичен җыелышып, бәйләм бәйлиләр. Октябрьдә бәрәңге бәйрәме уздырдык. Сабантуйлар да узмыйча калганы юк. Түгәрәкләр дә оештырам. Мәктәп укучылары белән дә эшлим. Дөрес, яшьләр дискотекага бик чыкмыйлар. Аларны җәйге ялларда гына үткәрәбез. Нәрсә бар, шуның белән эшлибез инде. Өйдән дискотека өчен ут шарлары да алып килеп куйдым. Менә бинабыз да матур булса икән ул... Котельныйда ремонт булгач, бәлки, безгә дә чират җитәр әле, дип бик ышанам мин, – дип, тыйнак кына елмайды Гөлнур.

Шушы кадәр тырышып көн итүче халыкка игътибар да, ихтирам да зуррак булырга тиеш кебек тоелды безгә.

Өмет

Авыл советын ниндидер административ бина дисәң, хәтерең калырлык. Кеп-кечкенә, салкын, ямьсез бүлмәдә башлык Валерий Чернышев белән бергә сәркатибе дә утыра. Җитмәсә, тәрәзәләреннән салкын җил өрә. Шулай да, сер бирмәделәр.

– Утырмаслык түгел үзе, шушында эшлибез инде, – диде сәркатип апа, матур гына елмаеп, кулын җылытычта җылыта-җылыта.

Валерий Чернышев әйтүенчә, план буенча, бинага быел капиталь ремонт ясалырга тиеш булган. «Тик илдәге хәлләр бу эшне артка чигерде», – диде ул. Хәер, бина быел гына да сафтан чыкмаган. Узган еллар да икътисад өчен авыр булды, ләкин башка районнарда программалар эшләп тора. Мондый бинага беренче чиратта игътибар ителерлек тә бит югыйсә.

– Киләсе елда булмасмы икән, дип көтәбез инде хәзер. Әлеге вакытта котельныйга ремонт ясадылар. Казаны искергән иде. Киләсе атнада газчылар рөхсәт бирсә, эшләтеп җибәрәчәкбез. Бу мәсьәлә үземә дә тынгылык бирми. Матур бинада эшләр идек, әлбәттә, – диде Валерий Чернышев.

Бу бинада, билгеле, ремонт белән генә чикләнеп кала торган түгел. Искесен тулысы белән сүтеп, яңа бина төзергә кирәк.

Әлеге мәсьәлә белән без Чистай районы башлыгы урынбасары Константин Ивановка мөрәҗәгать иттек.

– Әйе, без бу турыда беләбез. Урынга да берничә тапкыр чыктык, – диде ул. – Быел анда капиталь ремонт булмаячак. Киләсе елга уйлыйбыз, планлаштырабыз. Ләкин илдәге хәлләргә бәйле, төгәл җавап бирү авыр. Бина чыннан да иске, ләкин без яңаны төзи алмыйбыз. Бары тик төзекләндерә генә алабыз. Андый программага керер өчен, авылда яшәүчеләр саны күп булырга тиеш. Шулай ук иске мәктәп бинасына да кертә алмыйбыз, чөнки анда да ремонт кирәк. Һәм ул тагын да кыйммәткәрәк чыгачак. Әйе, мин сезгә зур вәгъдәләр бирә алам, ләкин алай эшлисем килми. Минем әле шул халык һәм сезнең алда әйткән сүзләрем өчен җавап тотасым бар.

***

Авыл апаларының кайсы белән генә сүз башласак та, аралашуны «колхоз беткәч, таркалгач...» дип сөйли башладылар. Димәк, шул елларда халыкның бер өлеше шәһәргә бәхет эзләп чыгып киткән, икенчесе, менә шулай тырышып, үз көнен үзе кайгырта башлаган.

Шулкадәр булдыклы халкы булып та, авыл ни өчен бетә соң? Җан әрнүе булып чыккан әлеге соравыбызга апалар менә ничек дип җавап бирде:

– Чөнки яшьләр юк диярлек, димәк, авылның киләчәге юк. Андыйлар берничә генә гаилә бар. Без хәзер шулай яшәп өйрәнгән, шунда төпләнгән инде. Булганына риза булып тормыш итәбез. Беркая да бара алмыйбыз, андый теләк тә юк. Авылда күңелебезгә хуш килгән хезмәтне табып яшәргә тырышабыз. Һәм, начар яшибез, дип әйтеп булмый. Кирәк әйберебезне алып, йорт-җирләребезне карап, матурлап, барасы җиребезгә барып торабыз. Без яшәгәндә, авыл яшәячәк әле. Заманалар үзгәреп, берәр эшмәкәр ни дә булса ачып җибәреп, эш урыннары булдырса, авылның киләчәге булырга мөмкин. Күреп торасыз бит, калган халык тырыша-тырмаша, һәркемдә мини-ферма, ләкин ул бары тик үзебез өчен генә. Авылның киләчәге булсын өчен, аны бергә туплаучы учак кирәк. Шуңа күрә мәдәният йортының матур итеп гөрләп торуын телибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

21 октябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Зөһрә Садыйкова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Ут һәм баскычны кайчан куярлар?

Без – Биектау районының Коркачык авылында яшәүче күпчелек халык шәһәргә электричкаларда йөреп эшлибез. Безнең авылдагы тукталыш «835 нче чакрым» дип атала. Платформаларның Казан шәһәренә бару өчен ясалган ягы бик әйбәт, ә менә кайтканда электричка туктый торган урыннан төшәр өчен баскыч ясалмаган. Кем ничек булдыра ала – шулай төшә. Әле ул тирәдә ут та юк. Караңгыда телефон уты белән йөрибез. Баскыч та, ут та булса, әйбәт булыр иде.

Биектау районы
Коркачык авылы халкы

«Горький тимер юлы»ның Казан төбәге матбугат үзәге:

– «835 нче чакрым» тукталыш пунктында шушы көннәрдә комиссия киңәшмәсе узачак. Тимерьюлчылар баскычны урнаштыру һәм платформада өстәмә яктырту юлларын караячак. Киңәшмәдә кабул ителгән карар турында сезгә соңрак хәбәр итәрбез. Проблеманы җиткергәнгә рәхмәтебезне белдерәбез, кыенлыклар тудырган өчен пассажирлардан гафу үтенәбез.

Подгузниклар өйгә килерме?

Подгузниклар мартка кадәр өйгә килде. Хәзер аны «Озон»нан электрон сертификат аша алам. Үзем сатып алам да, компенсациясе кире кайта. Подгузникны шушы тәртиптә алгач, мине исемлектән төшереп калдырмаслармы? Мин элеккеге тәртиптә өйгә килүен телим.

И. ХӘЙРУЛЛИНА. Азнакай

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан буенча төбәк бүлеге матбугат үзәге:

– Хәзерге вакытта безнең фонд ташламалы категорияләргә ия булган гражданнарны кирәк-яраклар белән өч юнәлештә тәэмин итә. Беренчесе – подгузниклар белән тәэмин итү буенча дәүләт контракты нигезендә. Шуннан соң товар килә һәм аны тарату башлана. Подгузниклар алучылар бездә бик күп. Шуңа күрә бу категорияне ике этапка бүлдек. Беренчесе инде тәмамланса, икенчесе 10 октябрьдә башланды. Икенчесе – компенсация түләү юлы белән алу. Гражданнар кирәк-яракларны үз акчасына сатып ала һәм шушы чек белән яшәү урыны буенча компенсация түләнә. Өченчесе – электрон сертификат ярдәмендә алу. 2021 елның октябреннән инвалидлар тернәкләндерү чараларын электрон сертификат аша алырга мөмкин. Товар «Мир» картасы аша сатып алынганда, компенсация кире картага кайта.

Хәзерге вакытта И. Хәйруллина быелның 23 октябренә кадәр электрон сертификат буенча – подгузниклар, 7 ноябрьгә кадәр җәймәләр белән тәэмин ителгән. Подгузникларның икенче этабы октябрьгә кадәр кайтарылачак. Шуннан соң И. Хәйруллина әлеге исемлеккә кертеләчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укучы сүзе

«АЛЬБИНАНЫҢ КҮҢЕЛ ЭШЕ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Һәрбер мәҗлескә өч төрле кеше килә. Берсе ләчтит сата, икенчесе хәлеңне белә, өченчесе урлаша. Бөтен кешенең дә авызын яулык белән томалап бетереп булмый. Арада шундый юньсез кешеләр бар, исең китмәсен. Акыллы кеше рәхмәт әйтә дә китә. Юләрләрне чәчен үстермиләр, үзләре тишелеп чыга. Мин андый явызларга яңадан борылып та карамас идем. Уңышлар сиңа!

РИММА

«ҖЫРЛАРГАМЫ, ЕЛАРГАМЫ?» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Кеше ничек итеп онытылып концерт карап утыра икән? Минем эчемдә утлар яна. Чөнки минем дә энемне алып киттеләр. Илдә тынычлык юк, артистлар җырлар инде ул. Аларның эшләре шул. Тик аларның җырларын тыңлап кына тынычланып булмый. Бу күңел ачуны азрак туктатып торсалар да була, минемчә. Мин үзем тыныч кына йоклый алмыйм. Илдә шундый тынгысыз бит. Шуны азрак уйлагыз да дога укыгыз Ходайдан сорап.

Нурсөя ХӘЙРЕТДИНОВА

***

Килешәм сезнең белән. «Пир во время чумы» дигән шикелле килеп чыга югыйсә… Нинди күңел ачып, уйнап-биеп-җырлап йөрү кирәктер? Бездә менә Өлкәннәр көнен дә билгеләп үтәргә рөхсәт бирмәделәр. Ә укытучыларныкын нишләптер тыймадылар… Төрле стандартлар инде, аңламассың…

Флюра НИЗАМОВА

Бер мең сум пособие ник юк?

Сезнең газетадан, Бөек Ватан сугышы инвалидлары, анда катнашучылар, фронтта һәлак булганнарның тол хатыннары, балаларына 1 мең сум пособие бирәләр, дип укыган идем. Минем әтием Шакир сугышта үлгән. Пенсия бүлегенә баргач, андый акча түләнми, диделәр. Менә шуны ачыклап бирегез әле.

Саймә ХӘСӘНОВА.
Әлмәт районы Яңа Кәшер авылы

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау бүлегенең матбугат үзәге:

– Безнең министрлык буенча Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның гаилә әгъзаларына 1 мең сум күләмендә өстәмә түләү каралмаган.

Россия Пенсия фондының төбәк бүлекчәсе матбугат үзәге:

– Түләүдә үзгәрешләр юк. Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, балаларына сез әйткән 1 мең сум күләмендә компенсация каралмаган.

Сез, мөгаен, дару урынына бирелә торган социаль пакет турында әйтәсездер. Быелдан дару өчен бирелә торган акчаның суммасы аена 1314,40 сумны тәшкил итә. Тик шунысын әйтергә кирәк: ул бары ай саен түләү (ЕДВ) алучыларга гына каралган. Социаль пакет сайлаган кеше дару гына алып калмый, шифаханәдә бушлай дәвалана ала. Аннан Бөек Ватан сугышы инвалидлары, анда катнашучылар, фронтта һәлак булганнарның тол хатыннары, балалары, Ленинград блокадасында булганнар, төрле бәрелешләрдә булган ветераннар, радиациядән зыян күрүчеләр һәм барлык төр инвалидлар файдалана ала. Социаль пакетны алу өчен, Пенсия бүлекләренә барып, гаризаны 1 октябрьгә кадәр язарга кирәк иде. Әгәр өлгермәгәннәр икән, моңа кадәр ничек алган, шул тәртиптә алуны дәвам иттерәчәкләр.

Яшь укытучыларга нинди ташламалар бар?

Мин вузда укытучылыкка укыйм. Авылда белем бирүче яшь мөгаллимнәр нинди ташламаларга өметләнә ала?

АЙГӨЛ. Арча

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге:

– Татарстан Министрлар Кабинетының 2018 елның декабрендәге «Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык өстәмә түләүләрне билгеләү турында» карары нигезендә, яшь белгечкә 1111 сум күләмендә өстәмә айлык түләү каралган. Ул укытучыга эшкә урнашкан көннән башлап, өч ел дәвамында түләнә. Авыл җирендә эшләгән белгечләргә ай саен 1388 сум өстәмә акча бирелә.

Су нигә җыелып тора?

Мин яшәгән Октябрьнең 60 еллыгы урамы, 2 нче йорт тирәсен «Безнең ишегалды» программасы буенча төзекләндерделәр. Тик 1 һәм 2 нче подъездлар юлдан аста калып, яңгыр яуганда, шунда су керә торган булды. Мин бу мәсьәлә буенча район җитәкчеләре янына бардым. Белгечләр, узган ел салынган асфальтны кисеп, июль аенда яңасын җәйделәр. Хәзер икенче проблема туды: яңгыр яуганда, йортыбыз кырыенда су җыелып тора. Миңа бу күренешне асфальт утырган дип аңлаттылар. Су кайчан җыелудан туктар?

Раилә ДУДКО.
Балык Бистәсе

Марс Мәгъдиев, Балык Бистәсе шәһәр тибындагы бистәсенең башкарма комитеты җитәкчесе:

– Бу проблемаларны төзүчеләргә җиткердем, нәтиҗәсен хәбәр итәрбез. Проблеманы уңай якка хәл итәргә тырышырбыз.

Җавапларны Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

17 октябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Татар халык җырлары» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 20.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники» 12+
01.05 «Ватандашлар» 12+
01.30 «Каравай». Национальные мотивы в творчестве композитора Ш.Тимербулатова 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Рәшидә Җиһаншина турында телеочерк 6+
12.35 «Кыргый океан серләре». Документаль фильм 6+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. Максим Матвеев. «ТРИГГЕР». НОВЫЕ СЕРИИ (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Андрей Смоляков, Александр Горбатов, Марина Александрова, Дарья Урсуляк, Сергей Газаров, Кирилл Зайцев, Александр Устюгов, Виктор Добронравов, Андрей Мерзликин, Филипп Ершов, Агриппина Стеклова. «ХУДОЖНИК» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.55 «СРОЧНО В НОМЕР! НА СЛУЖБЕ ЗАКОНА»

МАТЧ ТВ

06.00 Профилактика на канале с 6.00 до 10.00 часов
10.00, 12.55, 14.50 Новости
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Спортивный дайджест 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 04.05 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
13.50, 03.05 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
14.55 Смешанные единоборства. UFC. Алекса Грассо против Вивьен Арауджо. Трансляция из США 16+
15.55 «Громко». Прямой эфир
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Магнитогорск) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Москва) – ЦСКА. Прямая трансляция
21.45 Все на Матч! Прямой эфир
22.40 Тотальный футбол 12+
23.10 Самбо. Молодежный чемпионат мира. Трансляция из Армении 0+
01.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – МБА (Москва) 0+
03.00 Новости 0+
04.35 «Катар-2022». Тележурнал 12+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00, 00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
01.50 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Последняя воля» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.45 «ПЕРЕПУТАННЫЕ». 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «ЦЫГАНКА». 13-я – 15-я серии 16+
22.05 «Порча». «Медальон». «Снеговик» 16+
23.10 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.15 «Понять. Простить» 16+
01.10 «Тест на отцовство» 16+
02.50 «Давай разведёмся!» 16+
03.40 «Не отрекаются любя» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ДРУЖБА ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «ГОД СОРОК ПЕРВЫЙ». 1-я серия 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05, 03.25 «ПОД ПРИКРЫТИЕМ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «Защищая «Ворота Кавказа». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». «В.Александров. Тайна исчезновения учёного» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.45 «ДВА ДОЛГИХ ГУДКА В ТУМАНЕ» 12+
02.05 «Нюрнберг». Док. сериал 16+

18 октябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Татар халык җырлары» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Альбина Шагимуратова. Примадонна Востока и Запада 12+
00.45 «Каравай». Якутская выставка 6+
01.15 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Кыргый океан серләре». Документаль фильм 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Әнвәр Гобәйдуллин турында телеочерк 6+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
01.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. «ТРИГГЕР». НОВЫЕ СЕРИИ (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу. 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Андрей Смоляков, Александр Горбатов, Марина Александрова, Дарья Урсуляк, Сергей Газаров, Кирилл Зайцев, Александр Устюгов, Виктор Добронравов, Андрей Мерзликин, Филипп Ершов, Агриппина Стеклова, Светлана Колпакова. «ХУДОЖНИК» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+
02.55 Ярослав Бойко, Ольга Погодина. «СРОЧНО В НОМЕР! НА СЛУЖБЕ ЗАКОНА»

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 17.25 Новости
07.05, 14.55, 17.30, 22.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25, 03.05 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 04.05 «Катар. Обратный отсчёт» 12+
14.20 Автоспорт. G-Drive Российская серия кольцевых гонок. «Крепость Грозная» 0+
15.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Енисей» (Красноярский край) – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
17.55 Футбол. ФОНБЕТ Кубок России. «Локомотив» (Москва) – «Химки» (Московская область). Прямая трансляция
20.00 Футбол. ФОНБЕТ Кубок России. «Динамо» (Москва) – «Ростов» (Ростов-на-Дону). Прямая трансляция
23.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Майк Ричман против Айзека Дулиттла. Трансляция из США 16+
01.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «ПАРМА-ПАРИ» (Пермский край) – «Локомотив-Кубань» (Краснодар) 0+
03.00 Новости 0+
05.05 «Правила игры» 12+
05.30 «Голевая неделя. Суперлига» 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00, 00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.20 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
01.45 Остросюжетный сериал «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Монетка» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.45 «ПЕРЕПУТАННЫЕ». 5-я – 8-я серии 16+
19.00 «ЦЫГАНКА». 16-я – 18-я серии 16+
22.05 «Порча». «Жених». «Пелена» 16+
23.10 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.15 «Понять. Простить» 16+
01.10 «Тест на отцовство» 16+
02.50 «Давай разведёмся!» 16+
03.40 «Не отрекаются любя» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ПОД ПРИКРЫТИЕМ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «ГОД СОРОК ПЕРВЫЙ». 2-я серия 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир»16+
13.20, 15.05 «ПОД ПРИКРЫТИЕМ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости. 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «Прорыв «Голубой линии». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.45 «БЕЗ СРОКА ДАВНОСТИ» 12+
02.20 «Нюрнберг». Док. сериал 16+
03.00 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.25 «ПОД ПРИКРЫТИЕМ». 5-я и 6-я серии 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 17–23 ОКТЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Тормышыгыз яхшы якка үзгәрәчәк. Ләкин моның өчен тырышырга, үзегезне тота белергә кирәк. Әйтик, өстенлегегезне күрсәтергә маташып, берәрсен ялгыш кына үпкәләтергә мөмкинсез. Шуңа күрә мондый әйберләрдән сак булыгыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Бу атнаның төп девизы – хискә урынны азрак биреп, күбрәк эшләргә. Шулай булган очракта, озакламый кесәнең калынаеп китүенә сөенеп туя алмаячаксыз. Өстәвенә әле атна ахырында бик мөһим мәсьәләне хәл итеп куячаксыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Бердәнберегездән бүләк яки матур гына сюрприз көтегез. Суык тидерү куркынычы бар. Пандемия чорында нәрсә икәнен дә аерып булмый. Шуңа күрә, авырып китмәс өчен, җылырак киенеп йөрергә, иммунитетны ныгытырга тырышыгыз.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Бердәнберегез, үзегезне бәхеткә күмеп, бик шәп сюрприз белән сөендерер. Тик менә эштә генә берникадәр буталчыклык хөкем сөрер кебек. Сәбәбе аңлашылгач, барысы да үз көенә кайтыр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Атна сәеррәк кенә яңалыклардан башланыр. Начар дип әйтеп булмый аларны, әмма... Эшегездә бик мөһим чор башланырга тора. Югарырак вазыйфага күчерүләре бар, шул сәбәпле бераз гына дулкынланырга туры килмәгәе.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Эштәге хәлләрнең җайлы гына баруына карамастан, уяурак булу, тирә-юньгә ешрак караштыру зыян итмәс. Хезмәттәшләрегез арасыннан берсе сезнең урынга утырырга тели сыман... Исәп-хисап ясаганда да игътибарлырак булыгыз әле.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Өс-башны карау, йөз-кыяфәтне тәртипкә китерү өчен әйбәт чор. Яшерен-батырын түгел: эшнең көйле баруы, кешеләр белән уртак тел таба белү матурлык, пөхтәлектән дә тора.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Ачык йөзле, мөлаем, аралашучан булуыгыз катлаулы гына бер мәсьәләнең очына чыгарга ярдәм итәр. Җиңел генә! Бәйрәм көннәрендә туганнарыгыздан әйбәт хәбәрләр көтегез.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Беренче урында – эш. Шул сәбәпле шәхси тормышта бераз гына чаталык булып алмагае. Аның каравы кесәгезгә әйбәт кенә премия керер. Атна ахырларына таба бераз туарылып алсагыз, әйбәт булыр, юкса киеренкелек сәламәтлеккә зыян салырга мөмкин.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Бу атна уңышлы булачак. Шәхси тормышыгызда шатлык-куанычлар көтелә. Керем артуны вәгъдә иткән хәлләр килеп чыгачак. Көтелмәгән чыгымнар да булачак анысы, әмма алар сезнең өчен авыр йөккә әйләнмәячәк.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Ял итү теләге пәйда булыр. Эштәге, өйдәге киеренкелек һәм ыгы-зыгы кайтавазы бу. Күпкә түзгәнне, азга түзегез – бик тиздән барысы да көйләнәчәк.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Авызны кайчан ачарга, кайчан ябарга икәнен яхшы белгәнлектән, шөкер, өегездә кара тавыш чыкмый калачак. Хезмәт урыныңдагы күтәренкелек үзегезне бик нәтиҗәле эшләүгә этәрәчәк.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«ТАИФ» АҖ Директорлар Советы рәисе Рөстәм Султиев, әнисе

Зәйнәп Гайфулла кызы

вафат булу сәбәпле, РФ Дәүләт Думасы депутаты Ирек Борис улы Богуславскийның тирән кайгысын уртаклаша.
Ирек Борисович, Сезнең белән бергә без дә ихлас күңелдән кайгырабыз, иң якын һәм газиз кешегезне югалту ачысын бүлешәбез. Зәйнәп Гайфулла кызы игелекле һәм ярдәмчел кеше иде, аның турында якты хатирә безнең йөрәкләрдә гомерлеккә сакланыр.

Военный билет НП 7879541, выданный на имя **Нургалиева Зульфата Зуфаровича** 03.09.1978 г.р. военным комиссариатом Высокогорского района РТ считать недействительным в связи с утерей.

БОРЧЫМАСА, КАГЫЛМАСКА КИРӘК

Теш сызлаудан да яманы юк. Кемнәрдер тизрәк табибка барса, кайберәүләр дару төймәләре белән авыртуны басуны өстен күрә. Тешләрне ничек сакларга соң? Табибка кайчан барырга? Теш сызлауга түзәргә ярыймы?

Әлеге сорауларга 9 нчы стоматология поликлиникасы хирургы Илнур ӘХМӘТОВ белән җавап эзләдек.

– Тешләрне яшьтән сакларга кирәк. Тешнең ныклыгы аны һәрдаим чистартып торуга гына түгел, ничек туклануга да карый, – ди табиб. – Әгәр азык начар чәйнәлсә, вакланып бетмәсә һәм җитәрлек дәрәҗәдә юешләнмәсә, организм аны начар үзләштерә. Шунлыктан ашказаны һәм эчәкләрнең эшчәнлеге бозыла. Теш авырулары башка әгъзаларга да зыян сала. Әмма аны кеше сизми генә. Әйтик, теш аркасында йөрәк, буыннар, бөерләрдә авырулар барлыкка килә, теш казналары һәм яңаклар ялкынсына. Кан агуланып, кеше үләргә дә мөмкин.

Табиб, сабый балага 6 ай вакытында беренче тешләр чыга башлый, ди. Ике-өч яшькә кадәр аның авызында 20 теше булырга тиеш. Даими тешләр элек 7 яшьтән чыкса, хәзерге заман баласының инде биш яшендә барлыкка килә икән.

– Күкрәк сөте имгән сабыйларның тешләре нык була. Балаларның тешләре череп, үзе төшсә, тагын да әйбәт, – ди Илнур Әхмәтов. – Әти-әни баласына тешләрне сакларга кирәклеген даими аңлатып торырга тиеш. Элек без көнгә ике мәртәбә чистартырга кирәк дисәк, хәзер моны ашаган саен эшләргә тәкъдим итәбез. Ашаганнан соң авызны җылымса су белән чайкау да файдага. Ризыкны гел бер як белән генә чәйнәү дә киңәш ителми. Шулай ук гел йомшак ризыклар гына ашарга да ярамый. Болай эшләгәндә тешләрнең көче кими һәм алар тиз бозыла башлыйлар. Шуңа күрә чи яшелчәләр дә ашарга кирәк. Теш авырулары арасында иң еш очрый торганы – кариес. Бу вакытта теш авыртмый. Аны бары тик табиб кына күреп ала. Әгәр кариес эмальдән дентинга күчсә, тештә тишекләр барлыкка килә. Бу вакытта теш әледән-әле авыртып торырга мөмкин. Кайбер чакта теш салкын яки кайнарны сизә дибез, бу шул инде.

Кариес нәтиҗәсендә, эмаль һәм дентин аша микроблар пульпага үтеп кереп, аны бозалар. Пульпит вакытында теш төнлә һәм кинәт авыртып сызлый. Мондый тешне дәвалау озаккарак сузыла. Күп очракта авырту басылгач, табибка барып тормыйлар. Әмма болай эшләргә ярамый. Чөнки пульпасы (нервы) үлгән теш – микроблар үрчер өчен бик уңайлы урын. Тамырдагы каналлар аша микроблар периодонтка үтеп кереп, аның ялкынсынуын – периодонтит китереп чыгара. Табибка вакытында барганда мондый тешне дәвалап була әле. Ә инде соңга калган очракта, инфекция теш казнасына күчеп, сөяк ялкынсынуын (остеомиелит) барлыкка китерә. Бу очракта температура күтәрелә, яңак шешә. Мондый тешне алдырырга туры киләчәк.

Илнур Әхмәтов, акыл тешләрен үзем белгәнчә, тәртип белән алам, ди.

– Акыл тешен алдыру күпләрне куркыта. Әмма аның берние дә юк. Ул да башкалары кебек инде. Әмма акыл теше борчымаса, аңа кагылмаска кирәк. Хәзер тешләрне тигезләү модага кереп китте. Кайчакта, брекет куйдыра идем дип, берни эшләмәгән акыл тешен дә алуымны сорап киләләр. Алып җибәрәм инде. Әмма ул тешне алудан берни үзгәрми. Тешләр 25 яшькә чыгып бетә, аңкаудагы сөякләр 19 яшьтә үсүдән туктый. Алган теш урыны 20 елдан соң гына үзгәрә башлый, – ди ул. – Мин көненә 100 теш алам. Аларны чиләккә салсаң, яртысы тула. Тешне дәвалаучы табиблар миңа дип җибәрә икән, бу тешне алмыйча калмыйм. Тагын шунысы бар: хирургка кешеләр алдырырга кирәк булгач кына килә. Беркайчан да саклап калып булырдай тешне очратмадым.

Күп очракта теш алдырырга куркабыз. Илнур Әхмәтов исә, бар да табибтан тора, ди.

shutterstock.com

Табиб киңәше

✓Тешләрне ашаган саен чистарт.
✓Теш щеткасын ешрак алыштыр. Һәр кешенең үз теш щеткасы булырга тиеш.
✓Ашаганнан соң авызыңны чайка.
✓Тештәге калдыкларны махсус җеп белән ал.
✓Төрле температурадагы ризыкларны бер-бер артлы ашама.
✓Алма, кишер, суган һәм сарымсак тешләр өчен бик файдалы.



Теш алдырткач

✓Алдырган көнне авызны чайкарга ярамый.
✓Авыр эшләр эшләмәскә, иелмәскә.
✓Җылы киенергә кирәк.
✓1 сәгатьтән – эчәргә, ике сәгатьтән ашарга ярый.

Ниләр ашарга?

Тешләр өчен составында фтор һәм кальций булган ризыклар кирәк. Фтор балык, әстерхан чикләвеге, ипи һәм чәйдә бар. Кальцийга миндаль, ногыт борчагы, соя, көнҗет, йөзем, күрәгә һ.б. бай. Сөт продуктларын даими кулланыгыз. Шулай ук кәбестә, салат яфрагы, укроп һәм петрушка, кузгалак теш өчен бик кирәк.

– Кайчак зур гәүдәле ир-атлар да калтырап утыра. Әмма бер алдыргач, икенче килгәндә курыкмыйлар. Әгәр пациент белән үзара аңлашсаң, эшләү җиңел. Теш алдырырга килгәнсез икән, табибка ышану кирәк. Шулай ук табибның кешелекле булуы, җылы сүзне кызганмавы да мөһим. Авыруны бер сүз терелтә, диләр бит әле. Теш авыртканда андый сүзләрне кызганмаска кирәк, – ди табиб. – Мин һәр эшемне бисмилла белән башлыйм. Хәтта башка милләттән булган авырулар да теге доганы әйт әле, диләр. Шөкер, алган теш урыннары тиз төзәлә дә. Быел бер генә кеше дә, өзлегеп, кире килмәде. Тешләр сызлап интекмәс өчен, бер генә киңәш: вакытында табибка йөрегез. Елга бер тапкыр тешләрне күрсәтеп тору кирәк. Ипотека түлисен онытмыйбыз бит, тешләрне дә онытмыйк һәм саклыйк.

Агачлар да дәвалый

Имән дәрман бирә, йөрәк-кан тамырлары системасы чирләрен дәваларга ярдәм итә, ми эшчәнлеген яхшырта.

Чыршы яман тәэсирләрдән саклый, хәлсезлекне бетерә, куркудан, тынгысызлыктан арындыра.

Тал ярсучанлыктан коткара, баш авыртуын бетерә.

Балан хатын-кызларга бик килешә: күңелне тынычландыра, ярсуны баса.

Чаган көч бирә, күңелне күтәрә.

Юкә күңел төшенкелегеннән коткара, йөрәк-кан тамырлары системасына сихәт бирә.

Зирек чиктән ашкан көчне киметә, әмма аның янында озак торганда баш авыртуы, йөрәк кагуы ихтимал.

Усак артык киеренкелектән арындыра, авыртуны бетерә. Йөрәк авырулы кешеләргә аның янында озак торырга ярамый, тискәре йогынты ясавы бар.

Карагай канатландыра, мөһим ниятләрдә көч бирә.

Үзем сынадым

Шешенүдән котылдым

Аякларым шешеп тилмертте. Ни генә эшләп карасам да, ярдәм итми иде. Бер танышым рецепт бирде. Шуны эшләп, шешенүдән котылдым. Сезгә дә тәкъдим итәм.

Өч литрлы банкага бер стакан солы юып салдым, өстенә кайнатып суытылган су агыздым. Аны караңгы урында, 4–5 тапкыр болгатып, бер тәүлек тоттым. Аннан сөзеп, суыткычка куйдым. Солы суын күпме эчә аласыз, шуның кадәр эчегез. Шушы тәнәтмәне эчә башлагач, аякларымның шешенүе бетте.

Зөһрә НАСЫЙБУЛЛИНА. Чаллы

ЧӨГЕНДЕР ШИФАСЫ

1. Косметологлар бит тиресен яшь саклау өчен чи чөгендер согы кулланырга киңәш итә.
2. Фолий кислотасына бай чөгендер организмга яңа күзәнәкләр булдыру өчен кирәк.
3. Бу яшелчә организмны, канны, бөер һәм бавырны токсиннардан һәм агудан тиз чистарта.

Бөердә таш яки башка кимчелек булган очракта, эч киткәндә, ашказаны авыртканда чөгендер ашарга киңәш ителми.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

ТӘРТИП ҮЗЕҢНӘН БАШЛАНА

Өйдәге тәртип, чисталык күп очракта хатын-кызга гына кирәк сыман тоела. Күпме тырышып та өйне тәртиптә тота алмау, әлбәттә, нәфис затның ачуын чыгара, энергиясен ашый. Алай гына да түгел, бу хатын-кыз организмында кортизол бүленеп чыгуга да сәбәпче була икән. Ә стресс гормоны «уянган» өйдә тынычлык югалды дигән сүз. Тыныч та, ягымлы да булып калыйм дисәгез, әлеге киңәшләрне белеп тору зыян итмәс.

Алган җиреңә куй

Әгәр сез алган әйберегезне урынына куя белмисез икән, башкалардан тәртип таләп итүнең файдасы юк, димәк. Әлбәттә, бу юк сүз сыман тоелыр. Ә һәр әйбернең үз урыны булмаган йортта тәртип урнаштырып бетереп булмаячак. Әнәҗепнең, китапның, ачкыч яки аяк киеменең билгеле урыны булсын. Бүген анда, иртәгә тегендә икән, тәртип турында сүз дә була алмый.

Гадиләштерегез

Гаиләгезне тәртипкә өйрәтим дисәгез, гадиләштерү ягын карагыз. Нәрсәне дә булса эшләргә кирәк булганда, озын-озак һәм катлаулы итеп аңлатмагыз. Эшне башкару өчен аз вакыт һәм көч кирәк булган ысулны сайларга ярдәм итегез. Мәсәлән, почтага килгән газета һәм кәгазьләрне салу өчен ишек төбенә тартма куегыз, шунда салсыннар. Ә пычрак киемне салып ташлый торган урынга кәрҗин куйсагыз була.

Төгәл күрсәтмә кирәк

«Бар, бүлмәңне җыештыр!» – дигәндә, балалар сезнең нәрсә таләп итүегезне аңлап бетермәскә дә мөмкин. Карават астына оекбашларны яшереп, өстәл тартмасына аунап яткан кәгазьләрне тутырып куйгач та өй җыештырылган кебек күренә бит. «Җыештырылган бит, сиңа тагын ни кирәк?!» – дияргә мөмкиннәр. Ә уенчыкларны – тартмага, китапларны – киштәгә, киемнәрне – шкафка, чүпне кәрҗингә салырга, дип төгәл күрсәтмә биргәннән соң, алар бик тиз һәм яхшы итеп җыештырып куячак. Әлеге биремнәрне, баланың яшенә туры килә торган итеп, кәгазьгә язып куйсаң да комачауламас.

Урын җитсен

Әйберләрне кую, саклау өчен урын җитәрлекме? Балаларның бүлмәләрендә тәртип саклый алмауларының сәбәбе урын җитмәүдән дә булырга мөмкин. Бүлмәдә әйбер күп, куяр урын аз икән, баладан тәртип таләп итүнең мәгънәсе юк. Тартма тулы булса, «уенчыгыңны тартмага сал», китап киштәсе булмаган килеш, аны «алып куй», диюдән файда булмас.

Күңелле булсын

Җыештыруны күңелле итүнең төрле ысуллары бар. Көн саен кичке ашка кадәр яки кичке аштан соң 10 минут үз бүлмәңне булса да тәртипкә кертеп алуны гадәткә әверелдерү дә нәтиҗәсен бирми калмый. Моның өчен сәгать будильнигын куеп, гаилә белән бергә төгәл 10 минут җыештырып, тәртип ясап алырга була. Әлеге кичке «гадәт»кә берәр кызык исем тапсагыз да комачау итмәс.

Әлбәттә, эшне башкарганда да, кушканда да чама хисен белү мөһим. Өйне тәртиптә тоту хөкем карары түгел, ә файдалы гаилә гадәтенә әйләнгәндә, тәртип тә, тынычлык та булачак.

Белеп тор!

СУЫТКЫЧТА САКЛАМА

Суыткычта бозылмый дип, без бөтен әйберне шунда сакларга күнеккән. Ә менә кайбер азык-төлекне анда саклавың хәерлерәк икән.

✓ Консервланган азык-төлек һәм кайнатма. Алар болай да җитмәгән урынны гына биләп тора.
✓ Каты яшелчәләр (бәрәңге, кишер, суган). Аларны пластик яки агач тартмаларда саклавың яхшырак.
✓ Кавын, кабак. Алар суыткычта яхшырак саклана дигән сүз дөрес түгел.
✓ Тропик җимешләр. Алар түбән температурада саклаганда черми һәм зарарлы матдәләр бүлеп чыгара башлый. Цитрус җимешләрне дә шкафка күчерсәң яхшырак. Суыткычны шулай ук хөрмә белән гранат та яратмый. Аларны кәгазьгә төреп, бүлмә температурасында сакларга кирәк.
✓ Шоколад, конфетлар. Түбән температурада саклаганда, аларда аксыл катлам барлыкка килә. Әлбәттә, ул зарарлы түгел, әмма элеккеге кебек үк тәмле һәм матур булмый.
✓ Зәйтүн мае. Суыткычта саклаганда, анда лачаулар пәйда була һәм тәмсезләнә.
✓ Бал. Анда ул файдалы үзлекләрен югалта.

Тәмле булсын!

Гөмбә маринадлау

Зөлфия ДӘҮЛӘТОВА рецепты

Башта гөмбәләрне юып, 20 минут тозсыз суда пешереп алам. Аннары маринад әзерлим. Аның өчен 1 л суга 2 аш кашыгы шикәр комы, 2 аш кашыгы тоз, 2 аш кашыгы серкә, 2 аш кашыгы үсемлек мае салып кайнатам. Аннары 2 дәфнә яфрагы, 6 данә түгәрәк кара борыч, 2 тырнак сарымсак салып кайнатып чыгарам.

Чайкап алынган гөмбәләрне әлеге маринадка салып, 10 минут пешерәм дә стерильләштерелгән банкаларга тутырам.

«12 кашык» бисквиты

Эльмира ГАЛИМҖАНОВА рецепты

3 йомырканы яхшылап туглап, аңа 12 аш кашыгы шикәр комы өстәгез һәм блендер белән 2 минут күпертеп алыгыз. Әлеге массага 12 аш кашыгы сөт, 12 аш кашыгы үсемлек мае, ярты лимон согын өстәп, тагын туглагыз. Аннары12 аш кашыгы он, 1 кап камыр күперткеч салып, тагын болгатыгыз. Әзер камырны, майланган табага салып, 180–200 градуска кадәр җылытылган мичтә 20–25 минут чамасы пешерегез.

Саклау

МАЙЛЫ САРЫМСАК

Сарымсакны кышка саклауның бер үзенчәлекле ысулы бар. Аны майда да саклап була. Моның өчен сарымсак тырнакларын кабыгыннан чистартырга һәм стерильләштерелгән банкаларга тутырырга кирәк. Аннары өстенә көнбагыш яки зәйтүн мае салып, алдан тишекләр ясап куелган пластик капкач белән каплыйбыз һәм суыткычка куябыз. Болай әзерләнгән сарымсак 2–3 ай чамасы саклана. Сарымсак беткәннән соң, маен балык, бәрәңге пешерү һәм салатлар ясау өчен кулланырга була.

Үзем сынадым

«Кайнап» чистара

Кая гына барсак та, термос белән чәй алып йөрим. Тора-бара аның төбендә юып булмый торган пычрак катлам барлыкка килде. Юып кына бетерә алмагач, бер ысулны кулланып карарга булдым. Термоска бер чәй кашыгы сода һәм аңа ярты чәркә аш серкәсе салдым. «Кайнап» туктагач, аны селкеткәләп алдым да түктем. Әлеге ысулны өченче тапкыр кабатлаганда термосның төбе ялт иткән иде. Кулланып карагыз, зыянсыз чистарткыч кул астында гына бит!

Фәнүзә ИМӘНКУЛОВА. Арча

ЭТ-МӘЧЕ ДӘ МӘРХӘМӘТКӘ ЛАЕК

Хайван асрау – җаваплы эш. Тора-бара алар гаилә әгъзасына әверелеп бетә. Ислам динендә йорт хайваннарына мөнәсәбәт нинди? Кайсы җан ияләрен асрау тыела? Изге Коръәндә нинди хайваннар телгә алына?

Бу һәм башка сорауларга җавап табарга Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ ярдәм итте.

:: Мөселман кешесенә өйдә йорт хайваннары тоту рөхсәтме? Хәзер эт-мәче генә түгел, су чучкасы, елан, әкәмтөкәм, күсе асраган кешеләр дә бик күп.

– Йорт хайваннарына традицион рәвештә эт-мәче, мөгезле эре терлек, кош-корт, куян керә. Хайваннарны өйдә тоту рөхсәт ителә. Әмма, мәсәлән, эт шикелле хайваннарны өй эчендә тотарга ярамый. Ишегалдында, йорт-җирне саклар өчен ярый, билгеле. Гомумән, тормышыбызга куркыныч тудыра торган хайван була икән, аны өйдә тотмау хәерле. Ә песи мәчеткә дә кереп йөри ала, бу рөхсәт ителә.

:: Нинди җан иясен асрау гөнаһ санала?

– Дуңгыз асрау һәм өйдә эт тоту рөхсәт ителми. Пәйгамбәребез (с.г.в.) да: «Эт булган йортка фәрештәләр кермәс», – ди. Бәрәкәт фәрештәләре мондый өйне урап уза. Дуңгыз асрау – харам.

:: Ачулык тыелган эшме? Кайберәүләр хайваннарны ит өчен генә түгел, кызык өчен дә үтерә бит.

– Ислам дине буенча, әгәр дә моңа мохтаҗлык юк икән, ачлык янамаса, хайванны интектерү, кызык ясар өчен генә җан иясен аулау дөрес түгел.

:: Коръәндә нинди җан ияләре телгә алына?

– Бик күп җан ияләре искә алына. Урмәкүчтән башлап төрле кошларга кадәр. Аллаһы Тәгалә хәтта дөяне дә үрнәк итеп китерә. Кайсыларын йонын алырга, кайсыларының итен ашарга рөхсәт дип күрсәтә. Кайсыларына атланып йөрисез, кайсыларының сөтен кулланасыз, ди. Боларның һәммәсен дә Аллаһы Тәгалә искә ала һәм бер гыйбрәт булсын дип, үзенең кодрәте буларак китерә.

pinterest.com

:: Йортта яшәгән эт-мәче һәм башка хайваннарны күпләр кешедәй күреп тәрбияли. Хәтта киемнәр тегә, үзе ашамаган затлы ризыкны ашата. Мондый күренешкә динебез ни ди?

– Әйтүемчә, фатир эчендә эт тормаса, хәерлерәк инде. Асрыйбыз икән, бу очракта аларны тиешле рәвештә тотарга тиешбез. Ашату-эчертү, билгеле, тиешле, әмма артык исраф кылуга китерә торган гамәлләргә барып җитәргә кирәкми. Кыйммәтле киемнәр киертү, дисеңме... Әлбәттә, бу – һәркемнең үз эше. Әмма без билгеләнгән чикләрне узарга тиеш түгел. Исраф итү – начар гамәл.

:: Кайбер дүрт аяклы дусларны башта иялләштерәләр, аннан ташлап калдыралар. Бу гөнаһтыр бит?

– Пәйгамбәребез (с.г.в) бер хәдисендә әйтә: «Бер хатын песине бикләп куйганы өчен җәһәннәмгә эләкте», – ди. Ягъни ашарга табу юлсын да калдырмаган, песи ачтан үлгән. Аллаһы Тәгалә шуңа күрә аны җәннәттән мәхрүм итте. Хайван тотабыз икән, без алар өчен җаваплы. Әгәр дә без аларны ризык таба алмаслык итеп урамга чыгарып ташлыйбыз икән, бу бер дә яхшы түгел. Аларны карап, тәрбияләп тору – әманәт. Кыямәт көнендә алар да үз хакларын сорап киләчәк.

> – Берәү кое янында дымлы җирне ялап торган эткә тап була. Коега төшеп, аяк киеменә су алып, аны авызына кабып менә дә эткә су эчерә. Шушы гамәле өчен ул җәннәтле була. Җан иясенә карата рәхимле булганы өчен шундый зур дәрәҗәгә менә.
> – Сәхабәләр пәйгамбәрдән: «Әй, Аллаһның рәсүле, хайваннар өчен дә безгә савап булырмыни?» – дип сорый. Ул исә: «Әйе, һәрбер җан иясендә сезгә савап бар», – дип җавап бирә.
> – Пәйгамбәребез (с.г.в.) чапанында йоклап яткан мәчене уятырга теләмичә, чапанның итәген кисеп ала.
> – Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) бер хәдисендә: «Җирдәге мәхлукларга рәхимле икәнсез, Аллаһы Тәгалә сезгә дә рәхимле булыр», – ди.

Гыйбрәт өчен

ҺӘР НӘРСӘНЕҢ ХИКМӘТЕ БАР

Авыл тормышы белән яшәүче бер кешенең күзе тирес кортына төшә. Ул: «Кара әле, бу җирәнгеч һәм исле тирес кортының бу дөньяга яралуында нинди хикмәт бар инде?!» – дип фикер йөртә.

Шуннан соң, озак вакыт та үтми, әлеге кеше авырып китә. Нинди генә табибка барып, нинди генә дарулар эчеп караса да, чиреннән котыла алмый. Шулай итеп көннәрнең берендә аның юлына Һиндстан якларыннан килгән бер табиб очрый. «Авыруыңнан котылырга теләсәң, тирес кортларын киптереп, кайнар суда кайнатып эч», – дип киңәш бирә. Авырудан интеккән кеше табибның киңәшен үти һәм авыруыннан котыла. Үзенең тирес кортын кимсетеп каравын искә төшереп: «Әй Раббым Аллаһ, гафу ит мине, бу дөньяда яралган һәм яратылган бер генә мәхлук та болай гына, буш, хикмәтсез һәм урынсыз яратылмаган икән!» – дип тәүбә итә.

Югарыда сөйләнгән кыйссадагы хакыйкатьне Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында: «Бу дөньяда булган бер генә нәрсәне дә буш, кирәксез итеп яратмадым», – дип раслый. Шуңа күрә дөнья йортында күзебезгә чагылган бер әйбергә дә түбәнсетеп һәм кимсетеп карау ярамый. Күктәге ай, кояш һәм йолдызлардан алып җирдәге филгә кадәр, филдән алып тәннәребезгә энә кадап, каннарыбызны эчкән черкигә кадәр – бөтенесе үз урынында, үз эшләрен һәм вазыйфаларын башкара.

islam.ru

Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИНОВ

Йәгез, бер дога!

Кайгы-хәсрәт килгәндә укыла



dumrt.ru

«Әллааһүммә инни габдүкә үә бнү габдикә радыйтү хүкмәкә үә гадьләкә. Әсьәлүкә әң түзһибә ганнии гаммии үә хүзнии үә әң тарзүкании йүсьран лә гусьраа».

Мәгънәсе: «Аллаһым, чынбарлыкта мин – Синең колың һәм Синең колыңның баласы. Мин Синең хөкем итүеңнән һәм гаделлегеңнән риза булдым. Миннән борчуларымны, кайгымны куып җибәрүеңне һәм миңа җиңеллектән ризык бирүеңне, ә авырлыктан бирмәвеңне сорыйм».

Белеп тор!



Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Иң өстен зекер – «Ләә иләәһә иллъәллаһ», иң олы дога – «Әлхәмдүлилләһ» дип әйткән.

Тәҗрибә әһелләре: «Булдыра алган кеше көненә биш мең тапкыр «Ләә иләәһә иллъәллаһ» дип әйтсә, аның йөзендә нур, күңелендә тынычлык булыр; шушы көнне үлә калса, Аллаһ каршына иман белән кайтыр, ә инде «Әлхәмдүлилләһ» дигән доганы көненә биш мең тапкыр әйткән кешенең малында һәм ризыгында бәрәкәт артыр», – диләр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

Кызганыч, узган атнадагы санда чыккан уенда дөрес җавапны белүче булмады. Рәсемнәр астына без Хәния Фәрхи башкаруындагы «Авыл киче», Марат Яруллинның «Парым син» һәм Эльмира Сөләйманова репертуарыннан «Ярый әле дуслар бар» җырларын яшергән идек.

Бу җыр җилләр искәндә бөгелә торган агач һәм... җавапсыз мәхәббәт турында.

Әлеге җыр соңгы арада бик популяр. Сагынуларны басарга, болын чәчкәседәй матур кызлар янына, газиз туган җирләргә юл тоту турында ул.

Бу җыр исә иң кадерле кешеләребезгә багышлана. Тиз генә кайтып килүебез өчен рәнҗеп калмаска куша җырчы.

ИСЛАМИЯ ХӘМИДУЛЛИНА:

«ГАРМУН БӨТЕН КЕШЕГӘ КИЛЕШӘ»

Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка гармунчы кыз Исламия ХӘМИДУЛЛИНАны дәштек. Социаль челтәрләрдә күпләрне үзебезнең моңлы көйләрне башкарып, гашыйк итәргә өлгергән инде ул. Гармун кызларга килешәме? Исламияне гармун уйнарга кем өйрәткән? Без әнә шулар хакында сөйләштек.

:: Ни хәл?
– Хәлләр яхшы, Аллага шөкер!

:: Исемең бигрәк матур! Кем кушкан аны?
– Исемемне әби (әткәйнең әнисе) кушкан. Мәктәптә укыган вакытта яратмый идем аны. Нишләп барысының да исемнәре охшаган, ә минеке аерылып тора, имеш. Хәзер инде, гомумән, башкача уйлыйм. Исемемне бик яратам, шушындый үзенчәлекле исем кушканына әбиемә мең рәхмәтлемен.

:: Исламия, гармунда бик оста уйныйсың. Үзең өйрәндеңме, берәрсе өйрәттеме?
– Гармун уйнарга мәрхүм Нурулла бабам өйрәтә башлады. Миңа 16–17 яшьләр булганда «Әпипә»не уйнадым. Ноталар белмәсәм дә, гармунны кон дә кулыма алып, көйләрне ишеткәнчә уйный башладым.

:: Гаиләң турында да сөйлә әле.
– Гаиләбез иҗади, барыбыз да җырлыйбыз, гармун уйныйбыз. Бертуган абыем Инсафның музыкаль белеме дә бар, ул да – гармунчы.

:: Җырлы-моңлы йортта яши торып, иҗатка гашыйк булмый мөмкин түгелдер ул?
– Иҗат безнең яшәү рәвешенә әйләнде, дияргә мөмкин. Әби белән бабайга рәхмәт – моңга мәхәббәтне алар тәрбияләде. Җәйге каникулларда гел авылда була идем. Көне-төне җырлап йөргәнем, ә аларның мине тыңлап утырганнары әле дә хәтеремдә.

:: Кыз баланың нәфис кулларына гармун тарту авыррактыр ул, әйеме?
– Әйе, озаграк уйнасаң, кулларга төшә. Ләкин әз генә уйнап алсаң да, күңелгә шундый рәхәт булып китә, тынычландыра.

:: Гармун кыз кешегә килешми, диючеләр дә бар бит әле.
– Бу фикер белән һич килешмим. Гармун бит ул – бөтен кешегә килешә торган уен коралы.

:: Ноталар белмәсәң дә, күбесенчә шактый катлаулы, озын, моңлы көйләрне уйныйсың...
– Миңа элекке җырлар күбрәк ошый. Шулкадәр якын алар күңелгә. Мәгънәле дә. Ниндидер тирәнлек, күңелне айкап-чайкап чыга торган сер бар. Мин бигрәк тә «Шахта» көен яратып уйныйм. Әби белән бабай да гел элеккеге җырлар җырлый. Шуңа каныма сеңгәндер инде ул.

:: Исламия, зур сәхнәгә чыгу турында хыялланасыңмы?
– Мин бик оялчан бит. Хәтта туганнарым янында да җырларга оялам. Сәхнә турында хыялланган вакытлар бар иде. Ә хәзер хыяллар башка.

:: Җырлаганыңны, гармун уйнаганыңны социаль челтәрләргә урнаштырганда, бу оялчанлык комачауламыймы соң?
– Институтны тәмамлагач, – ди ул, – мин Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә эшләдем. Кызыксынып китеп, шушы темага кагылышлы документларны җыя бардым. Аннан миңа АКШка, Калифорния штатына барып чыгарга туры килде. Язмыш кушуыдыр инде, анда революция вакытында Россиядә хезмәт иткән ветеран офицерлар белән очраштым. Казаннан икәнемне белгәч, тарихчы да булгач, алар Россиянең алтын запасы турындагы үзләрендә сакланган материалларны миңа бирергә булдылар. Өлкән яшьтә булып, күбесе 80нән узган иде инде. Китапта бернинди уйдырма да юк, нигезендә әнә шул документлар ята.

Дәүләт банкы

Ни өчен Россия империясе вакытында да, революциядән соң да ил байлыгы Казанда тупланган? Бу сорауга җавап элеккеге Зур Проломная, хәзерге Бауман урамындагы дәүләт банкы бинасына бәйле булып чыкты. Россия империясенең дәүләт банкына Александр II указы белән 1860 елның 31 маенда, реформалардан соң нигез салына. Казан бүлеге исә 1864 елның 15 июнендә Кремльдә сафка баса. Әгәр Зур Проломная урамында хәзинә саклау урыннары белән яңа бина төзелмәсә, Казан банкы, бәлки, тарихка кереп тә калмас иде. «Алтын келәтләре»н карап чыкканнан соң, Мәскәүдән килгән кабул итүче комиссия болай дип язып калдыра: «Алтын саклау өчен бик уңайлы. Шәһәр халкы ышанычлы». Бер ай элек кенә Беренче Бөтендөнья сугышы башланганлыктан, яңа бинага яшерен генә күченәләр.

Алтын яңгыры

Россия Беренче Бөтендөнья сугышына 1914 елның 1 августында керә. Сентябрь ахырында банкның яңа идарәчесе яшерен шифр белән сугылган телеграмма ала. Анда тимер юл вокзалында 77 тонна алтын коелмасы төялгән махсус транспортны кабул итеп, короллы сак астында «алтын келәт»кә урнаштырырга кушыла. Соңрак Казанга 6500 данә алтын коелмасы килә. Бу – зур эшнең башы гына була әле.

1915 елның 19 июнендә алтын Петроградтан китерелә. Банкның Себердәге, Мәскәү, Самара, Тамбов, Козель шәһәрләрендәге бүлекләре бөтен байлыкларын Казанга таба юллыйлар. Революциядән соң Россия империясенең алтын запасы пролетариат диктатурасына күчә. Юридик яктан ул халыкныкы булып санала. 1918 елның маенда, немецлар Мәскәү юнәлешенә юл алгач, Владимир Ленин Казандагы алтын запасы өчен борчылуын белдерә. Хәрбиләр аңа бернинди дә куркыныч юклыгын дәлилләде. Әмма Казандагы алтын запасы ул вакыттагы вакыйгаларга үзе үк төсмер бирә дә инде. Мондый байлыкка хуҗа булу большевикларның да күзләрен кыздыра, каршы якны да үзенә чакыра. Казанны яулап алу генштаб подполковнигы Владимир Каппельгә тапшырыла. Банктагы алтынны сакларга исә полковник Иоаким Вацетисның латыш укчылары полкы һәм Мулланур Вахитов җитәкчелегендәге интернациональ батальонның татар мөселманнары алына.

Дошман якынлаша. Мәскәү алтын запасын эвакуацияләү көне итеп 1918 елның 5 августын билгели. Әмма соң була инде. Нәкъ шул көнне чех легионерлары Казанны артиллерия утына тоталар. Шәһәрдә паника куба. Көндезге сәгать 11ләрдә Каппельнең 400 офицеры банктан ике чакрым гына ераклыктагы Постау бистәсенә, ә Поповка, Кукушкино һәм Татар зираты тирәсендә чех легионерлары мөселман отрядларына һөҗүм итә. 1918 елның 7 августында иртәнге сәгать 4тә серб легионерлары банкка бәреп керә һәм идарәче урынын били.

Эшелон

Владимир Каппель Казаннан алтынны чыгару өчен бик үзенчәлекле юл уйлап таба. Банк янына шәһәрдә булган 30 трамвайны китертә. Ул вакытта трамвай юлы Зур Проломная урамыннан Бишбалта бистәсендәге Елга портына кадәр сузылган була. Алтынны трамвайларга 20 тәүлек буена көнтөн төйиләр. Кара эшне татарлар башкара. Шулай итеп, бар байлык Самарага китә.

> 20 көн эчендә Казаннан биш пароходта һәм бер баржада Россиядәге алтын запасының 73 проценты чыгарыла. Гомуми авырлыгы 80 мең пот була: 8399 әрҗә коелган һәм пластиналардагы алтын, 2468 капчык алтын акча, 18 сумка һәм 900 әрҗә көмеш, акча ассигнацияләре. Шулай ук төрле чит дәүләтләрнең алтын акчалары.

Самарада 40 махсус вагоннан торган «алтын эшелон» төзелә, 12 вагон сак хезмәткәрләре өчен тәгаенләнә. Эшелон 13 ноябрь көнне Омскига килеп җитә. 18 ноябрьдә адмирал Колчак Омскида Россиянең Югары идарәчесе дип игълан ителә һәм барлык алтын запаслары аның карамагына күчә. «Алтын эшелон» гел Колчак янәшәсендә була. Әмма 1920 елның гыйнвар аенда чех командованиесе адмиралны тоткарлый һәм Кызыл армиягә тапшыра. 7 февральдә Колчак Иркутскида судсызнисез атып үтерелә. 1920 елның 18 мартында Владимир Ленин «алтын эшелон» калдыкларын кире Казанга кайтару турында фәрман чыгара. Дөрес, Колчак карамагында булганда алтын инде 250 тоннадан артыкка кимегән була. Акча белән саналганда, бу – 41 миллион сум дигән сүз. Хәер, адмирал кулына эләккәнче үк, алтынның шактый өлеше юкка чыга.

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

Талау

Равил Ибраһимов алтын запасы дүрт тапкыр вәхшиләрчә таланган дип фаразлый.

Беренчесе. Җинаять 1918 елның август ахыры – сентябрь башында Казанда кылына. Бу җинаятькә ачылган оператив эш «Алтын руно» дип атала һәм хәзергә кадәр архивларда «үтә яшерен» тамгасы белән саклана.

Икенчесе. 1919 елның 31 октябрендә, Көнчыгышка юл алу өчен алтын запасын вагоннарга төягәндә, 60 мең сум алтын акча тутырылган бер капчык юкка чыга. Күләме чагыштырмача аз булганлыктан, белгечләр монысына әллә ни игътибар бирмиләр.

Өченчесе. Бу талау Себердә Зима һәм Тыреть станцияләре арасында була. 1920 елның 11 гыйнварында 13 әрҗә алтын акча урлана.

Дүртенчесе. Адмирал Колчак Россиянең алтын запасын дәүләт байлыгы итеп саный. Аның язмышы большевикларны җиңгәч хәл ителер дип уйлый. Әмма сугышны алып бару өчен акча кирәк була. Шуңа күрә 1919 елның мартында акча «чүлмәге»н ачарга карар кылына. Дүрт эшелонны Владивостокка җибәрәләр. Һәр тиен акча, һәр коелма исәптә була. 1919 елның сентябрендә Чита шәһәрендә атаман Григорий Семенов бишенче эшелонны кулга төшерә. Анда 44 миллион сумлык алтын була. Соңрак ул 29 миллионын армия ихтыяҗларына тотуы, ә 15ен расписка белән японнарга тапшыруы турында күрсәтмәләр бирә.

Собакинодагы хәзинә

Казан тирәсендә алтын эзләүчеләр күп була. Хәтта чит илләрдән дә киләләр. Болар барысы да беренче фаразга бәйле. Күләме күп булганлыктан, 1918 елның 28 августында Самарага бөтен байлыкны да төяп җибәрә алмыйлар. Аннан соңгы көннәрдә исә су буйлап җибәрергә мөмкинлек калмый: Кама Тамагы территориясенә Петроградтан миноносец килә. Аклар командованиесе калган алтынны кая булса да яшерергә карар кыла. Августның соңгы көннәрендә калган алтынны җигүле атларга төйиләр. Документлардан күренгәнчә, «алтын конвой» Балык рәтләрен үтә, Грузин урамына чыга. Шәһәрне чыкканда сул якта чиркәү кала. Ул вакытта Арча зираты белән бүгенге Горький паркы урнашкан урыннар шәһәр чите була. Аннан Себер тракты буенча тимер юлны кисеп үтәләр һәм Нократ – Уржум трактына чыгалар. Биектаудан 7 чакрым ераклыктагы Собакино (бүгенге Калинино) авылыннан соң урманнар башлана. Олы юлдан авыл юлына чыккач, тагын өч чакрым баралар. Урман эчендә зур бер чокыр янына туктыйлар. Хәзинәне күмәләр...

Конвой составыннан бер кеше генә исән кала. Ул – поляк Константин Ветеско. Канга батып яткан җирдән аны крестьяннар табып алалар да, дәвалап, аякка бастыралар. Ул шунда шактый яши әле, еш кына чокыр янына барып кайта. Шушы җирлекнең планын төзи. Тик тиф авыруы аны аяктан ега. Үзе янына абыйсы Вячеславны чакыра. Ул вакытта Польша Россия составында була. Энесен җирләгәч, абыйсы кире туган иленә кайтып китә. Чокыр янына барырга насыйп булмый аңа, аның каравы энесе биргән акчага утар сатып ала, гаиләкора. Тик Казандагы алтын запасы аңа тынгылык бирми. Танышлары аша элемтәгә кереп, Франция һәм Бөекбритания белән бергәләп, алтын эзләү экспедициясе оештырырга ирешә. 1929 елның 1 октябрендә өч илнең вәкилләре Казан вокзалына аяк баса. Тирә-якгагы авылларга 16 экспедиция ясыйлар. Тик Россия аларның эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр була.

Алтын запасының табыласына ышанычыгыз бармы? Мөгаен, бу – китап авторына бирелгән сораулар арасында иң кызыксындырганы булгандыр. «Өмет һәрвакытта да булырга тиеш», – диде Равил Ибраһимов һәм серле генә елмайды. «Өч-дүрт айдан бу китап өстәмәләр белән чыгачак, чөнки керми калган документлар бихисап әле», – диде ул.

Китап авторы булачак фильмыннан өзекләр дә күрсәтте. Китап эше тәмамлангач та, кино төшерү белән шөгыльләнмәкче ул. Кем белә, 25 еллык эшнең төп ноктасы булып, хәзинә дә табылып куяр әле.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

«АНДЫЙ БАЛАЛАР ЯШӘРГӘ ТИЕШ ТҮГЕЛ»

РУХИ ГАРИПЛЕКНЕҢ СӘБӘБЕ НИДӘ?

Бер бала турында язганнан соң, аның әнисенә килгән СМС-хәбәрләрне укыгач, яңадан кулыма каләм алдым.

vk.com

Без кыйммәтле дарулар белән генә торучы бала турында язган идек. Вакытында дару эчмәсә, баланың өянәкләре башлана. Әнисенең йокысы туйганчы йоклаганы, тынычлап утырып ашаганы да юк. Ул гел баласы янында. Калдырып, беркая да китә алмый. «ВТ»да язмышы бәян ителгәч, аңа ярдәм кулы сузучылар күп булды. Бер белмәгән кешеләр редакциягә акча алып килде. Бирәүләр исә 3 кап кирәкле дару китерде. Әни кешенең сөенечтән елап шалтыраткан чаклары да булды. Көннәрдән беркөнне ул безгә үзенә килеп ирешкән хәбәрләрне юллады. Аларны укыгач, чәчләр үрә торырлык. Бер СМСта: «Без синең белән бергә укыган идек. Хәтерлисеңме, бу мин – Айсылу. Син ничек оялмыйча газета аша балаңа акча җыеп ятасың? Ул бит инде йөри алмаячак, утырып та тора алмагач, нәрсә дип ул баланы яшәтергә соң? Андый балалар яшәргә тиеш түгелләр. Мин бүген бик зур оешмада эшлим. Кесәм тулы акча. Әмма синең балаңа бирмим. Мин аны этләр приютына җибәрәм. Алар, ичмасам, кешеләргә юаныч», – диелгән сүзләр дә бар иде. Икенчесе бөтенләй таныш булмаган кешедән. Анысы: «Шалкан кебек тик яткан балаң сиңа нәрсәгә соң? Үзең өчен яшә», – дип язган.

Әллә нишләп киттем. Әлеге хәбәрләрне укыгач, ике көн уйланып йөрдем. Кая бара бу дөнья? Шулкадәр борчулы, тынычсыз вакытта бер-беренә мондый сүзләр язып буламы икән? Нигә дип күңелләрне рәнҗетергә соң? Авыру бала үстергән әни үз хәлен үзе генә беләдер! Миңа мөрәҗәгать иткән ханымны юатыр сүзләр таба алмасам да, балаң турында уйла, дип кенә киңәш бирә алдым. Ә бит һәр сабыйга әни кирәк!

Дөрес, авыру бала үстерү җиңел түгел. Авыру икәнлекләрен белгәч, күбесенең әтиләре гаиләләрен ташлап китә. Ә хатын-кыз болай эшли алмый. Ничек итсә итә, баласын ташламый. Ул аны дәвалау, терңәкләндерү өчен бар көчен куя.

– Нинди генә булса да, үз балаңа авыр сүз әйттерәсе килми, – ди Балтачтан авыру бала тәрбияләүче Разилә Мәхмүтова. – Ирең дә, туганнарың да ярдәм итсә генә авырлыкны күтәрү җиңел. Мондый чакта акча белән ярдәм итү генә түгел, кайчак бер җылы сүз дә җитә. Сүз дә юк, арып киткән чаклар да була. Әмма үзеңдә көч табарга кирәк. Кешедән ишеткән авыр сүз бик кыен. Миңа да кайчандыр каты бәрелгәннәре булды. Әмма мин авыру балам белән яшәргә өйрәндем. Мин аны башкалардан бер җире дә ким түгел дип кабул итәм. Нишләтим соң инде?! Димәк, Аллаһы Тәгалә безгә сынау биргән. Без аны үтәргә тиеш.

Арабызда авыру бала күрмәгән, алар белән очрашмаган яки очрашырга теләмәгән кешеләр дә юк түгел. Казанга терңәкләндерү үтәргә килгәч, Разилә балалар мәйданчыгындагы кызы янында баласын читкә алып китүче әнине искә төшерде.

– Нигә бу кыз сөйләшми, нигә йөрми? – дип сорый сабый. Әнисе тиз генә әләктереп алды да, баласын алып китмәкче була. Ә мин исә аларны туктаттым. Сабыйга кызым турында сөйләдем. Әгәр син аның белән уйнасаң, ул сөенәчәк, дидем. Бала үзгәреп китте. Дөрестән дә, без алга таба шундый күңелсез хәлләр булмасын өчен сабыйларны кечкенәдән дөрес тәрбияләргә, яңәшәләрендә авыру балалар барлыгын да аңлатырга тиеш, – ди Разилә. – Шулай иткәндә генә, аларга карата җылы караш булачак. Бергә укыту да кирәк дип уйлыйм мин. Үзләре йөгереп йөргән, ә иптәшләренең утырып кына торуын, аларның ярдәмгә мохтаҗ икәнен күрсәләр, күңелләрендә миһербанлык уяныр иде.

Элек әби-бабайлар, авыру балалар башкаларга гыйбрәт өчен туа, ди торган иде. Ә без аларны күреп гыйбрәт алабызмы соң? Ни өчен кешеләр бер-берсенә авыр сүзләр яза, ни өчен каты бәрелеп, күңелләрен рәнҗетүдән курыкмый? Психолог Алла Шаиновага шул сорауны бирдек.

– Соңгы вакытта кешеләр усалланды. Элек әйтәсе килгән сүзләрен эчләренә йотсалар, хәзер теләсә нәрсә язар өчен социаль челтәрләр барлыкка килде. Начар сүзләр язучылар кешегә авырлык китерәм дип уйламый да. Ул үз эшен эшли. Язып куя да күңеле бушап кала. Башкалар хакында уйлап торучы юк хәзер, – ди ул. – Мондый сүзләргә игътибар итмәскә кирәк. Аны язучылар үзе турында да, башкалар турында да уйламый, хәтта яшәү мәгънәсен дә аңламый алар. Андыйларны үзгәртеп булмый. Алар шулай өйрәнгән инде.

Эт өрер, бүре йөрер, ди безнең халык. Авыр хәлгә калгач, ярдәм сорамыйча да булмый. Без шул эшне бергәләп башкарабыз да инде. Газета укучылар белән ике арада игелек күпере салабыз. Булышуыбызны сораган хатлар безгә гел килеп тора. Җир йөзендә мәрхәмәтле кешеләр бик күп! Шуңа да күңелләрне төшермик. Авыруларга сихәт, аларны тәрбияләүчеләргә сабырлык телик.

Ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәндә кирәк:
- ✓ авыр хәлдә калган кешенең мәгълүматлары;
- ✓ авыру тарихы, диагнозы, дәвалау кирәклеге турында белешмә;
- ✓ элемтәгә керер өчен телефон номеры;
- ✓ банк реквизитлары.

МИН ӘЛЕ ДӘ АНЫ КӨТӘМ...

Ләйсән Абдуллинаның шәхси архивыннан

Мөслимдә яшәүче Ләйсән Абдуллина өметен өзмәскә тырыша. 15 сентябрь көнне Мәскәүгә эшкә дип чыгып киткән ире Рамил юлда фаҗигагә юлыгып вафат була. Өченче сабыен көткән Ләйсән ул көннәрне искә төшерү белән елый башлый. Ул әле дә ирен эшкә генә киткәндер дип яши.

– Без ирем белән 2014 елда гаилә корып җибәрдек. Бер елдан улыбыз Шамил туды. Аны вакытыннан алда таптым. Балам 1 килограммлы иде. Улыбызны тиз генә өйгә дә кайтармадылар. Өченче УЗИ узганда ук, табиблар баланың кимчелекләрен күреп алган иде. Күңел белән башкалар төсле булмас дип көтсәм дә, авыру туар дип уйламаган идем, – дип сөйли Ләйсән. – Тикшеренә торгач, балада ДЦП икәне ачыкланды. Табиблар өметне өзмәде, дәваланырга кирәк дип тордылар. Бар тормышыбыз Шамил тирәли тәгәрәде. Елаган чаклар да булды. Әмма янымда иремнең булуы, аның җылы сүзләре миңа яшәргә көч бирде. Без кулдан килгәнчә Шамилне дәваларга тырыштык.

Ләйсән Шамилне кая гына йөртми. Малайның куллары тыңласа да, аяклары тик тормый икән. Әнисе, улына ярдәм итәр өчен, Түбән Хастаханәсенә үк барып җитә. Анда Шамилнең аякларына операция ясагач, алар тынычлана.

– 2021 елда ирем белән киңәштек тә тагын бер бала алып кайтырга булдык. Ул чакта күренмәгән табиб калмады. Озакламый тупырдап торган малаебыз туды. Мин гел Шамил белән булгач, ирем Рамил декрет ялы рәсмиләштереп, яныбызга кайтты. Ул монда чакта җиңел иде әле. Быел кечкенә балабызга яшь ярым тулды. Ирем үз машинабызда Мәскәүгә эшенә киткән иде. Ноябрь аенда яңадан кайтасы иде ул, – ди Ләйсән.

Алар өченче бала алып кайтырга уйламаган да була. Ләйсән авырга узганын белгәч, ире дә, үзе дә шатлана. Җитмәсә, табиблар кыз көткәннәрен әйтә. Рамил хатынына авыр буласын аңлап, өченче бала белән декрет ялын да үзенә рәсмиләштерергә уйлый. Мәскәүгә баруы да шуның өчен була. Тик кайтып кына җитә алмый... Чувашия юлында аварияга очрый.

– Кызымны февраль аенда туар дип көтәм. Әле, шөкер, анализларым да яхшы. Тик күңелем генә кителгән. Хәлем бик авыр. Шамилем авыру булмаса, тырмашып булса да яшәр идем әле. Тик берни үзгәртеп булмый. Миңа түзәргә, көчле булырга, елап утырмаска кирәк, – ди Ләйсән.

Ярдәм итүчеләре дә юк түгел. Үзенең әти-әнисе, туганнары ташламый. Каенанасы да гел янәшә. Балаларны гел ул карап тора икән.

– Без Шуганка авылында яши идек. Андагы йортыбыз бик иске. Шамил еш авыргач, Мөслимгә күчтек. Кеше фатирында торабыз. Баланы юындырырга да кирәк бит. Шәһәр фатирында уңайлы, – ди Ләйсән. – Дөньяда мәрхәмәтле кешеләр җитәрлек. Көтмәгәндә генә ярдәм кулы сузып куялар. Шамилнең өянәкләре булмасын өчен, әле дә терңәкләндерү үзәкләренә йөртеп торам. Аллага шөкер, акренләп үзгәрешләр сизелә. Алга таба Аллаһы Тәгалә җаен бирер әле дип яшим. Сабыйларым хакына сабыр итәргә кирәк. Авырлыклар артта калыр, матур көннәр алдадыр әле!

Бу гаиләгә ярдәм итәргә теләүчеләр өчен Ләйсәннең телефон номеры: **89872792614**. Әлеге номер Ләйсәннең әтисе Фоат Кыям улы Хаҗиев исемендәге Саклык банкы картасына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЗИФА КАДЫЙРОВА:

«КАДЫЙРОВА ЯМАН БАЙДЫР, ДИЛӘР»

Зифа Кадыйрова язучы түгел, диләр иде элек. Хәзер андый сүзләр ишетелми. Ник дигәндә, Зифа КАДЫЙРОВА әсәрләре укучыга китап рәвешендә генә түгел, спектакль булып та барып җитә, геройлары экраннарда да күрсәтелә. Танылу артында ни ята? Без шул хакта һәм хәзерге вазгыять турында әңгәмә кордык.

:: Зифа апа, быел укучыларны «Урланган яшьлек» китабы белән сөендердегез. Аның кулъязмасы янгында юкка чыккан иде кебек.

– Әсәрне бит башлыйсың да читкә алып куясың. Шуннан ул үз сәгатен көтеп ята. Вакыты җиткәч, үзеннән-үзе языла. Ә утта янган кулъязмага килгәндә, аларны кире кайтарып булмый инде. Мин башта алынган прототипларга да кире кайтмадым. Чөнки тупланган түл, очраган язмышлар бик күп. «Урланган яшьлек»не мин бакча өе янганнан соң башлап куйган идем инде, язылуы көз, кыш айларында булды. Ул өр-яңадан язылды. Аның белән кызыксынган режиссерлар да бар инде. Әйтик, Уфаның «Нур», Буа театрлары соратып алды. Әлмәт театры да кызыксына. Төрле режиссер төрлечә ача аны.

:: Дистәгә якын китап, шуларның дүртесе рус теленә тәрҗемә ителгән, инде хәзер үзегезне авыз тутырып, язучы, дип әйтә аласызмы?

– Аны мин әйтергә тиеш түгел, әйтсә, халык әйтә. Халык язучы буларак кабул итә. Очрашулардан кайтып кергәнем юк. Кызыксыналар, сорыйлар, чакыралар. Әмма Язучылар берлегенә керә торган китабым язылмаган әле. Мин шулай дип уйлыйм.

:: Халык кабул иткәч, берлеккә керергә вакыт җиткәндер инде. Язучылар сезне язучы дип атыймы соң?

– Берлеккә кермәгәч, язучылар язучы дип санамыйлар икән *(көлә)*. Дөрес, анда атлыгып тормыйм. Минем – үз юлым. Әле менә Санкт-Петербургка үземә юл ачтым. Питер татарлары мине чакырды, мин Буа театры режиссеры Раил Садриевны чакырдым. Бергәләп татар китабын пропагандаладык.

Китапларны урыс теленә дә үзем тәрҗемә иттерәм, мөхәррирен дә яллыйм. Чыгару мәшәкатен дә үзем башкарып чыгам. Китапны урысчага тәрҗемә итеп бастыру бик кыйммәткә төшә. Ләкин телен белмәгән татарлар да күп бит. Аларны да игътибардан читтә калдырасы килми. Өстәвенә, мондый очрашуларны берәү дә әзерләп куймый. Үзем табам, китапларымны төяп, үзем барам, аларны сатам, аралашам. Юлы да, башкасы да фәкать үз хисабыма. Шушы очрашуларга мин бик рәхмәтле. Кайчак залдан шундый сорау яңгырый: аңа җавап биргәндә, күңелдә яңа әсәр языла башлый.

:: Сезнең әсәрләргә театрлар да бик теләп алына. Алар арасында күңелгә иң якыны кайсы, аерып әйтә аласызмы?

– «Синсез килгән язлар»ны Әлмәт театры да, Башкорт драма театры да куйды. Һәркайсы үзенчә ачкан, һәркайсы үзенчәлекле. Башкорт режиссеры Айрат Абушахманов, мәсәлән, мине аңлар өчен, актерлары белән кунакка килеп китте. Хәзер «Яраларың белән яратырмын» дигән әсәрне куярга җыена. Сөенечкә, ел саен бер премьера булып тора. Дөрес, режиссерларның кайбер фикерләре белән килешеп тә бетеп булмый, алар театр кануннары белән эш итә, минем – үз кузгалавым. Әйтәләр бит әле, жирафның муены озын, ул күбрәк күрә дип, шуның шикелле.

:: Әсәрегез буенча «Сөмбел» фильмы төшерелде. Тагын кайсы әсәрегезне экраннарда күрергә теләр идегез?

– «Бәхеткә юл кайдан?» әсәрен экраннарда күрергә теләр идем. Аны кызыксынып сорап алучылар да булды. Кызганыч, финанс мөмкинлеге тапмадылар. «Көтеп узган гомер», «Язмыш сынавы» – алары да фильмга ятышлы булыр иде. Китапларны үз көчем белән чыгарсам да, фильмнарның иганәчесе була алмыйм шул.

:: Язучылык белән акча эшләп буламы соң?

– Кайберәүләр, Кадыйрова яман байдыр, диләр. Аллага шөкер, мин бик бай. Минем укучыларым бик күп. Чыннан да, китап белән тормышны алып барып була. Чөнки минем халыкны беркайчан да китапсыз тотканым юк. Китапны чыгарам, ул сатыла. Шулвакыт элек чыккан китап сатуда бетеп китә. Яңасыннан кергән керем элеккесен кабатлап бастыруга тотыла. Китапларым берсенә берсе әнә шулай ярдәм итә. Ерак җирләргә очрашуларга баргач, китапларыгызны Казаннан табып алып кайтабыз, диделәр. Хәзер инде укырга теләүчеләргә эшне азрак җиңеләйттек. Минем китапларны «Озон» аша да алып була. Кайбер өлкәләрнең матбугат чаралары әсәремне урлап бастыралар. Әйтик, Түбән Новгородта шундый хәл булган. Рөхсәт сорасалар да, каршы килмим юкса. Берсеннән дә гонорар сораганым юк. Һич югы әйтсәләр, күңел булыр иде. Аларны гаепләмим, чөнки бастырылуы – китап таралуга файда.

:: Гадәттә, балачактан ук язучы булырга хыялландым, дип сөйлиләр. Ә сез?

– Утыз яшемне тутыргач, тормышта нәрсәнедер үзгәртергә кирәклеген тойдым. Тик нәрсә икәнен генә аңламыйм. Бер караганда, тормыш бара, төзелештә эшлим, балалар үсә. Әмма аларга авторитет булырга да кирәк бит әле. Әни, балалар минем белән горурлансын өчен, нәрсә эшләргә? Кешегә бит тагын бер мөмкинлек бирелергә тиеш. Мин язып караган кеше түгел, әмма кәгазьнең күп нәрсәдән коткарганын чамалый идем. Шулай итеп, беренче китапны 48 яшемдә үзем өчен яздым.

> Гаиләдә проблема бар иде, шуны чишә алмыйча, төнлә йоклый алмый интеккән вакытта кулга каләм алдым. Кем уйлаган ул әйберне кемдер укыр дип? Мин аны хәтта кучереп тә язмадым.

Хәер, беркайчан да күчереп язып утырганым булмады. Шул 540 бит кулдан-кулга китте. Әле бит ул кыек-мыек языла, чөнки фикерне төшереп өлгереп булмый. Башка шулкадәр күп мәгълүмат килә иде, хәзер алай түгел инде. Димәк, бер генә нәрсә дә мәңгелек була алмый. Ә теге кулъязманы бер 60лап кеше укыгач, эзләп табып алдым. Аңарчы эштә багана башында янып үлгән ир-ат турында сөйләгәннәр иде, мин шуны яза башладым. Укучы өчен максатчан «Бәхеткә юл кайдан?», «Урланган яшьлек» китаплары язылды, алдагылары үзем өчен.

:: Язучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

– Заманнан бер адым алда барырга тиеш. Ир-ат язучылар тарихны белергә тиеш, дип уйлыйм. Әле менә югары сыйныф укучылары белән очрашуда булдык. Шунда егетләргә, укыгыз, укымаган кеше белән тормыш итәргә кызык түгел, дидем. Үземнән чыгып әйтәм. Минем ирем укымышлы булды. Аның белән сөйләшү, аралашу кызык иде. Надан кеше белән ни турыда сөйләшәсең инде? Сөйләшергә сүз дә булмый бит андый очракта. Дөрес, замана тизләнде, аның артыннан җитешү дә ансат түгел. Ә икенче яктан кешене артка сөйрәүче нәрсәләр икеләтә артты. Шул ук «Tik Tok» рухи үсеш бирми, ә вакытны ашый.

:: «Мин язучы түгел», – дисез дә, ә бит сезне «татар әдәбияты феномены», диләр. Танылу артында ни ята? Тырышлыкмы, уҗатлекме яки башка берәр төрле сыйфатмы?

– Нәрсәсе феномендыр аның, күп җирдә шулай язалар инде. Үзеңне укысыннар, сине танысыннар өчен, укучы белән тотрыклы диалог булырга тиештер. Мин күп йөрим, сез әйткәнчә танылу килсә дә, әллә кемгә әйләнмәдем. Мин – шул халыкның гади бер баласы. Очрашуларга биш кеше килсә дә, 100 кеше килсә дә, сөйләшәм, беркемнең үтенечен кире каккааным юк. Ирем вафат булгач та, атна азагында очрашулар билгеләнгән иде. Барысын да йөреп чыктым. Халык белән аралашу ул чакта минем өчен хәсрәттән котылу чарасы булды. Очрашуларга башта ирем белән бергә йөрдек, аннары кызым йөртә башлады. Кайларда гына булмадык. Башкортстанга да чыгып китә идек, Татарстанны да аркылыга-буйга йөрдек. Әле бит ул чакта кызым рульдә рәтләп йөри дә белми иде. Чакыралар икән, мөмкинлегем юк дип тормадым, машинага китапларны төйибез дә китәбез. Мөгаен, халык белән еш аралашкангга, кеше холыкларын әйбәт өйрәнгәнмендер. Миннән, психология китапларын укыйсызмы, дип сорыйлар. Бернәрсә укымыйм. Мин тормышны күзәтәм. Бу эшне язучылык дип тә, башкача да бәяләмим. Минем өчен ул – Алла кушкан эш. Олыгайган көндә шушы сәләт ачылмаса, әдәби юл булмаса, ничек яшәр идем, дип тә уйланам. Ирем янына да кеше күп җыела иде, минем янда да халык күп. Ниндидер миссия инде бу.

:: Минем янымда кеше күп дисез, ә сынауларны узганда, ярдәм итүчеләр булдымы соң?

– Кем ничек ярдәм итсен инде? Беркемнән дә ярдәм сораганым, ялынганым булмады. Кешегә тормышында сынау бирелә. Аны ничек бар – шулай кабул итәргә кирәк. Үзеңне җәллисең икән, бирешәсең, ахыр чиктә кемнеңдер җилкәсенә авырлык булып ятасың. Иң куркынычы – кемнеңдер кулына калу. Шуны аңласаң, нинди генә сынау килсә дә, аякта басып калып була.

Минем тормышымда сынаулар күп булды. Алар барысы да баштан үткән, мине чыныктырган һәм артта калган инде. Аңа рәхмәтле булырга кирәк. Ул я тормыш башында, я азагында килә. Менә бүген дә без сынау алдында торабыз. Мобилизация бара. Бер ана, баламны җибәрмим дип, күз яшен түгә. Мин дә җибәрмим, син дә җибәрмә... Ил алдында аналар күз яше түгә. Иң җаваплы чорга кердек. Без балаларыбызны нишләтик, ничек саклап калыйк? Барысында да шушы сораулар. Шул вакытта мин балама, әнә тегенеке барсын, син барма, дип әйтә алмыйм. Телем әйләнми моңа. Минем улым да, киявем дә, оныгым да китәр яшьтә. Менә нинди олы сынау безнең алда. Шуны ничек абруйны сындырмыйча үтәргә? Бу заманда кешенең кешелеклелеге нык күренәчәк. Качып йөри торган замана түгел. Саклап та, сатып та алып кала торган замана түгел.

:: Сезнең геройлар – хатын-кызлар, аналар... Тик аларны бәхетле дип әйтеп булмый кебек.

– Хатын-кыз гына түгел, ир-атлар да. Алар бер-берсеннән башка яшәми. Китапларымда нигездә гаилә темасын күтәрәм, сәясәткә кагылмыйм. Аның өчен махсуслашкан аерым язучылар бар. Тарихны язу да һәркемгә бирелми. Минем максат – ир-ат затын күтәрү. Ир баланы этиләр тәрбияләсен, кызлар яхшы ана булсын дип телим. Гомер үткәч кенә балага яхшы тәрбия бирмәвең беленә. Иң авыр кайгы – балаң белән аңлаша алмау. Аңа югары белем бирүгә караганда, кешелек сыйфатын тәрбияләү мөһимрәк. Шулай булгач, минем герой ул – гаилә. Ә бәхеткә килгәндә, исән кешегә кылган хаталарны төзәтергә һәрвакыт мөмкинлек бар. Үлгәннәр генә бернәрсә дә төзәтә алмый. Исән кеше ни дә булса төзәтә ала.

> Тормышта күп кеше, вакытында гафу үтенә алмаганлыктан, үзенең җәзасын ала. Гафу үтенү бәхеткә илтә. Ә инде үз гаебен танымыйча, гел кемнедер гаепләп яшәгән кешенең тормышы туктап кала, ул үсә алмый. Тора-бара авыруларга урала...

:: Әниегез сезнең романнарны укый идеме, нинди әни иде ул?

– Әни юк кына әйбердә дә матурлык күрә белә торган кеше иде. Укырга ярата иде. Гомер буе сыер савучы булып эшләде, иртәнге сменадан кайтканда, бармак буе чәчкәләрне җыеп, матур итеп букет ясап, стаканга куя иде. Гап-гади авыл хатынына гади күз күрмәгәнне күрә белү кайдан килгән? Китапка ихтыяҗ ничек туган? Шулар турында тора-тора уйланам. Мин мәктәптә укыганда китап белән дус булмадым. Мәктәптән кайту белән, фермага ярдәмгә ашыктык. Язучы, җырчы булу хыялга да кермәде. Ә әни – үзгә кеше. Ул һаман матурлык эзләүдә булды. 78 яшендә курчак ясарга өйрәнде. Аны ясый, кием тегә, бармагына балдакка чаклы кидерә, кулчатыр тоттыра, сумкасын әмәлли. Бармаклары тотмый башлагач кына бу шөгылен ташлады. Ул курчаклар хәзер безгә истәлеккә калды.

Әнинең башта минем яза башлавыма әллә ни исе китмәде. Аннары кеше сүзе колагына кергәнме, укып карарга сорый башлады. «Бүген язмадым», – дисәң, «Бер юл да язмадыңмыни?» – дип, чын күңеленнән гаҗәпләнә иде.

:: Балаларыгызда, оныкларыгызда сезнең кебек язу сәләте бармы?

– Юк. Мине бит бу юлга тормышның бер авыр мизгеле китерде. Алар да язучы булсын дип теләмим, ләкин ризыклары шунда икән, бернишләр хәл юк.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

УМАРТА

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

Аның әле беркайчан да тормышка бу кадәре үк аек караганы юк иде. Ул беркайчан да бу кадәре тере түгел иде. Юк, үлми әле ул, үтерергә ашыкмасыннар!

Камил атылып диярлек болдырга чыгып басты. Тере икәнлеген иң элек үз-үзенә раслар өчен, күкрәк киереп сулу алды. Көзнең боз исе кергән салкын һавасы җылы канны уятып, үпкәләргә төшеп утырды. Авыл өстенә эленгән кичке тынлыкка да үзенең тере икәнлеген расларга кирәк иде: Камил ишек тупсасына ук терәп куелган кабакка җен ачуы белән китереп типте. Кабак тонык тавыш чыгарып очып китте дә шундый ук тонык тавыш белән дөп итеп җиргә килеп бәрелде, һәм урталай ярылып, аның бер кисәге акрын гына җиргә янтаеп төште. Келәт янында үсеп утырган карт шомырттан бер көтү чыпчык фыррр итеп күтәрелде дә, тагын нинди тамаша булыр икән дигәндәй, электр чыбыгына тезелешеп утырды. Ишегалдына төче кабак исе таралды. Менә! Менә нәрсә өчен кайтырга кирәк булган икән авылга! Аңа чын исләр, чын төсләр кирәк иде. Сирәк очрый, тотып, капшап була торган. Тормышның чыны монда икән. Әхмәт дусты юкка гына чакырмаган...

Камил кабакка якын ук килеп, җиргә тезләнде, аның йомшак, сусыл эченә борынын төртте. Иреннәре белән төшләрен капшап тапты, бер-икесен авызына алып, шул килеш кенә чәйнәп төкерде.

25 яшендә туган авылында ярык кабак эченә башын тыгып торганда, әллә кайчангы бер көнне исенә төшерде. Сирәк була торган көннәрнең берсе иде ул.

Ул вакытта Каракүл зур булмаса да, һәр өендә бишәр-алтышар кеше яши торган 60–70 ихаталы бер авыл иде. Өйләре бәләкәй, бүрәнәләре дә әллә ни эре дип әйтерлек түгел. Шулай да хуҗалыклар ныклы, бөтен авыл белән умарта корты тоталар. Кемнең кем булуына карамастан, каракүлләләр бал кортларына бердәй мөнәсәбәттә иде. Бөтенесенең ихатасында аллы-гөлле умарталар рәт-рәт тезелеп утыра. Бакча артларында юкә тезелеп үсә. Арасында – алмагачлар. Ашаганнары да, эчкәннәре дә – бал гына. Каракүл халкының бөтен авыруга бер дәвасы бар – прополис, бал, балавыз.

Күл буенда урнашканга, авылга шуның исеме бирелгән иде. Кара күлнең үзенең дә риваятьләре бик күп. Гомер узган саен, дәверләр алышынган саен, яңалары өстәлә бара.

Күлдән ерак түгел Кама ага. Ул елны, яз җиту белән, елга ярларыннан ташып чыкты, күлне дә узып, авылның аскы урамына ук килеп терәлде. Яшелчә бакчасы су астында калды. Су киткәнне дүрткүзләп көттеләр. Су көтүлекләргә дә җәелгән, көтү йөртергә болынлыклар кирәк. Авыл халкы эшсез тора алмый, бакча да үстерәсе бар. Каракүл халкы тирә-як авыллар арасында беренчеләрдән булып помидор үстерә башлаган иде. Быел да помидорлары белән шаккатырасы килә аларның. Һәм көннәрдән бер көнне су китте. Ул иртәне авылның йөрәге булып, көннәр буе тек-тек басып, урамнарны урый торган Миңнегали карт, таң беленүгә, хәбәр салды:

– Анда, анда, – дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, абына-сөртенә ашыгып атлый иде ул. Оекбашларына чалбар балагын пөхтәләп кыстырып кигән, җилкәсенә салган камчылы чыбыркысының сабы атлаган саен селкенеп, аркасын төя, ләкин ул боларның берсенә дә игътибар итми. Кәкре бармагы белән Кама ягына күрсәтә. Әле капкаларын ачарга өлгермәгән Каракүл халкы Миңнегали картның шаукымын әллә каян тоеп алды. Сыер сауган җирләреннән хатыннар чиләкләрен тоткан килеш урамга чыгып бастылар.

Артларыннан ирләре баш тыкты.

– Анда, – дип көчкә тын ала-ала сөйли Миңнегали карт, эчкә баткан яңаклары сүз әйткән саен аска-өскә йөреп тора, тешсез авызы белән иреннәрен чәйни, – алагаем балык, күзе минем йодрык кадәр, үзе биш үгез чаклы! Валлаһи менә! Иткәччәйләр, иткәччәйләр бит, әй! Ал бидрәңне, пычак ал, әйдә, – дип туктап та тормый теркелди үзе. Авылның икенче очына җиткәнче, аңа шактый гына кеше ияргән иде инде. Миңнегали карт очына-җилпенә, кагына-кагына халык җыеп, яшелчә бакчасына таба төшеп китте. Теге балык чыннан да зур, ахрысы, авылдан ук түмгәк булып күренә. Су килгәнчегә кадәр, анда бернинди түмгәк тә юк иде, авыл халкы аяк очыннан күз күреме кадәре араны биш бармагы кебек белә. Ирләрдән генә торган төркем төшеп җитте, дигәндә, авыл ягында ачы итеп чыбыркы шартлаганы ишетелде. Кем икән, диясе дә юк, болай итеп чыбыркы Зарифә генә шартлата ала. Алмачуар атының өстендә йоклый ул, кайчан карама, иярдә. Аның чыбыркы шартлаткан тавышы Каракүлне имләп кенә тора, ишетелми башласа, юксындыра башлый. Миңнегали карт авылның сагында торса, Зарифә – каравылда. Фермада төнге каравылчы булып эшләве көндез өенә дә ияреп кайта. Уяулыкларына күз тимәсен. Бу юлы Зарифә соңга кала язды, шуны явызлыгы белән кайтармакчы: айгырын камчылый-камчылый, туп-туры ирләр өстенә ажгырып килә.

– Туктагыз, туктагыз! Имансызлар, туктагыз, хәзер милициягә шалтыратам, башыгызны төрмәдә черетәм мин сезнең! – дип кычкыра-кычкыра килеп терәлде ул ирләр янына, айгырын биетеп.

– Шалтыратам мин сиңа! – Мостафа төркем алдына ук чыгып басты. Кулындагы балтасының йөзен дә ялтыратып алды. Күр, янәсе. Зарифәнең ирдәүкәләген болай да җене сөйми иде аның, монда да башбаштакланып йөрмәкче була. Башка вакыт булса, Мостафа башы белән вакланып тормас та иде. Мостафа – балта остасы, авылдан авылга чират торып чакырып торалар үзен йорт салырга. Ул да коралын кулыннан төшерми, йоклаганда баш астына куеп ята, диләр. Сакалын да балта белән кыра, ди. Бервакыт базар көнне каенесе Шәкүр белән сүзгә килеп, бөтен кеше күз алдында балта белән тегесенең мыегын кырып алган иде. Шуннан бирле Шәкүрнең мыегы үскәне юк.

– Синнән сорап торганнар, ди монда! Хатының бәбәйгә тулгаклый анда, бар, кайт, районга алып барасың булса... Монда үләксә каравыллап йөргәнче, хатыныңны кара! – дип, Мостафага гына карап сөйләде Зарифә.

Аннан бөтенесенә берьюлы:

– Кагыласы булмагыз, козгыннар! Ләйлинур түткәй төшмичә торып, якын да килмисез! Имансызлар! – дип кычкырды. Зарифәне Мостафа гына куркытырлык түгел иде. Ирләрдән курыкмаска ул төнлә фермада каравылда торганда өйрәнде. Кемнәрне генә күрмәде ул төннәрен. Янына наз өмет итеп килгәннәре бер хәл әле, алары эт булып өрергә дә, кушсаң, күләгәгә әйләнергә дә риза. Каракүл юлында йөрүчеләрнең иманы бөтенләй юк – аларын куркыту өчен иң элек үзеңә курыкмаска кирәк. Төн уртасында йокламаган кеше болай да хәтәр: үзенең куркулары, шикләре белән сине түгел, үз-үзен дә танымый әле ул. Ә Зарифәнең боларны төнлә, дөм караңгыда, әнә шундый чакларында күргәне бар. Шуңа да өстән генә карый ул аларга. Мостафаның да авырткан җирен белә: уң кулының беләзеге ычкына аның, тоткан әйберләре төшеп китә. Мостафаның бар курыкканы шул: бөтенләй тотмаска әйләнсә, нишләр?

– Әбекәй белән Газраилнең эше күп бүген: Самат корткасы үләргә ята, «Йасин» чыгарга китте! – Әхмәт әбисенең исеме яңгырауга телгә килде. Балык дигән бу гыйфритне күреп, ул шүрләп калган иде. Эченнән сиздерми генә «ләхәүлә»сен кабатлый.

– Каракүлдән гыйфрит чыккач, ахырзаман җитәр, диләр иде, әнә чыккан да инде! – диде ул, вәсвәсәләнеп. – Самат корткасы да үлсә...

Җыелган халык пошынып, үзара карашып куйды. Әхмәт әйткәннәр аларның да күңеленә килгән иде.

– Әнә гыйфритең чыккан да бездәге якты тормышны күреп, гарьлегеннән үлгән, – дип төрттереп алды аксак Хәләф. Ул үзе Каракүлдән балык тотып кайтканда, мотоциклдан егылып, сул аягын тубыктан өздергән иде. Өзелгән аягы ялганмады, протез киеп йөри. Балык җене кагылган иде аңа, көне-төне балыкка чаба торган гадәте бар. Каракүл халкы болай җенләнгәнне бер дә өнәп бетерми: үз башыңа ашкынасың, ди. Хәләфкә дә: «Әле ярый аяк белән генә котылдың, күл иясе җаныңны да сорар», – дигән сүз ишеттерүчеләр дә булды. Аксак Хәләф мондый хорафатларга кул гына селтәде. Минем урында коммунист Зәки булса, аңа да шулай дияр идегезме, дип шаркылдап көлде.

– Әбиеңнең әкиятләрен өйләнгәч тә тыңларга өлгерерсең әле, – дип төрттерде берәү Әхмәткә.

– Чү, оланнар, әнә коммунист Зәки килә, – дип, Миңнегали карт авыл ягыннан килүчеләргә ымлады. Авыл халкы чүлдәге дөяләр кебек бер сызыкка тезелешеп, бу якка агыла иде, алдан Зәки бара. Тәгәрмәчләренә балчык уралып, әйләнми башлагач, мотоциклын карт өянке төбендә калдырып, җәяү атлый. Зәкигә «коммунист» сүзенең кушамат булып тагылуы да аның чыннан да сул карашларда торуыннан түгел иде. Каракүлдә җәмгыятьне беркайчан да уңга һәм сулга бүлеп карамадылар.

Түгәрәк дөньялары белән бергә әйләнә иде алар. Әйләнгән саен, элек уң дигәне хәзер сулда кала, сул дигәне уңга әйләнә бара – моңа әллә кайчан төшенделәр инде. Колхоз төзергә кушкач, төзеделәр. Социалистик ярышта катнашырга дигәч, артка да калмыйча, алга да чыкмыйча эшләп йөрделәр. Авыллардан кулакларны чүпли башлагач, чекистлар аптырап бетте: бакчасында кимендә кырык умартасы булган, келәтендә мичкә-мичкә балы утырган кешене кайсы төркемгә кертәсең? Каракүлдә исә бөтенесе дә шундый. Сыйнфый дошман эзләп килгән чекистлар Каракүлдә өйдән-өйгә йөреп, бер атна ятты.

Дәвамы бар >

СУПЕРМАРКЕТ ӘДӘПЛӘРЕ

Нәрсә алырга теләгәнегезне кибеткә барганчы ук уйлагыз. Язып куйсагыз да була. Шул очракта вакытыгыз да янга калачак, киштәләр янында чират та булдырмассыз.

Суыткычны озак ачып тормагыз, азык-төлек бозылырга мөмкин. Тышлыктагы язуны укыганда суыткычны ябып тору мәслихәт.

Танышыгызны очратсагыз икән, хәләхвәл белешеп, «бөке» булдырмагыз. Урамга чыккач сөйләшерсез.

Әгәр дә кире уйлагансыз икән, сатып аласы әйберегезне теләсә кайда ташлап калдырмагыз. Иң кулае – аны кассада калдыру.

Тележканы юл өстендә тотмагыз, җыйнаграк йөрегез. Соңыннан аны үз урынына илтеп куйсагыз – сезгә «бишле»!

Чиратта торганда дистанцияне саклагыз. Вируслардан качу өчен генә түгел. Пандемия булмаган вакытта да кешенең үз аулак мохите булырга тиеш.

Акчагызны, банк картасын, дисконтка, мобиль кушымтаны алдан әзерләгез. «Кызым урнаштырган иде, каядыр бар ул минем», – дип, кассада телефон актару бер дә матур түгел.

Чират торган арада кинәт кенә яңа кассаны ачсалар, әтешә-төртешә чабасы түгел, яме!

Кайбер кибетләрдә экспресс-кассалар бар. Анда товарны үзең пипелдәтеп түлисең. Тик алар бер-ике әйбер алучылар өчен генә. Әнә сез әнә күпме әйбер җыйгансыз.

Иң мөһиме, шуны истә тотыгыз: сез кешедән нинди тәртип-мөнәсәбәт көтәсез, алар да сездән шуны ук көтәләр. Һәр җирдә итагатьле булыйк! Әйдә, узыгыз, тоткарламагыз чиратны.

Әз-мәз мәзәк

* * *

Ниһаять, көзге депрессия килде! Җәйгесе туйдырган иде инде.

* * *

– Бабай, мин сиңа сокланам, 95 яшеңдә дә әбиемә «Матурым» дип эндәшәсең...

– 10 еллап элек исемен оныттым шул, улым.

* * *

– Улыбызның туган көнен быел кайда үткәрергә дә белмибез. Аквапаркта, кафеда, картингта – бөтен җирдә булдык инде.

– Ә без үсгәндә туган көнне ике генә җирдә үткәреп була иде: кухняда һәм залда.

Сканворд сораулары: Экс-Казан егете; Афзал Шамов «... мәче»; Инану; Кунак ... каршы-каршы; Өметне акламаган боз; Казандагы төп югары уку йорты; Өсәк, арҗа; Телевизор уйлап табучы; ...-әче, ...-әшәке; Ясалма тешләр; Әби коралы; Һинд озын борыны; Опера тексты; Кыр; Очып киткән су; Импортлы шалаш; «... моң» бәйгесе; Хан тамгасы; «Фольксваген» төре; Шайтаннар башлыгы; ... Яхин; Туйдә кычкыралар; Бүрәнәләрдән өелә; ... Расих; Милек хуҗасы; Ялтыраткыч; Уянгач була; Бизәк; Актанышта Әнәк күршесе; Атлет чөя; Ачыган камыр; Электр каршылык берәмлеге; Зиндан; ФИОдагы Ф; Гугл көндәше; Орышу; Килен-йолалы рызык; Кул асты; Арча һәм Теләче авылы; ... Ишморат; Юнәлеш күрсәтү символы; Ашказаны авыруы; Казанның оча торган тәлинкәсе; Боксчы мәртәбә китте; Кисәкчә; Экрандагы язу; Тәртипсезлеккә өндәүче рызык; Сәер формалы балык; Кешегә охшаган җанвар; Рус эстрадасы җырчысы; Драма әсәре өлеше; «... и Диод» шаяннар һәм тапкырлар командасы; Түбә асты; Грек хәрефе; Сабантуй чабышкысы; Коронавируста аны сизмиләр; Татарлар яратып эчә; Чае булган рус мужигы; Фәләкъ сурәсеннән соң; Пистолет; Японнар балыкны шулай ашый; Русчасы – ласка.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Соры, Артур, ашы, лар, КФУ, протез, әп, вигвам, Иләһи, тугра, иблис, әче, полироль, бура, сырлама, ия, өн, Яндекс, ар, гастрит, титр, нокаут, азу, цирк, чорма, акт, маймыл, тәм, чәй, Иван, ләтчә, Джастин.

Вертикаль: Мәтәскә, Пучы, Риза, гер, ук, пар, апара, Вавилов, Ом, Триод, Атилла, тәрмә, Туарег, камбала, су, Зворыкин, Нәс, орчык, токмач, ТТ, фамилия, чи, вышану, Быянка, Лайсан, фил, уч, либретто, басу, ки, ро, Рөстәм, Фидан, ат.

Беләсең килсә...

1 Либрокубикуларист ул:

а) китапларны арттан укырга яратучы;
б) китаплар җыеп аны укымаучы;
в) китапларны урын өстендә укырга яратучы.

2 Бу шәһәр Казаннан 7536 чакрымда урнашкан:

а) Хабаровск;
б) Магадан;
в) Владикавказ.

3 Россиянең тышкы эшләр министры Сергей Лавров ничә тел белә?

а) 4;
б) 5;
в) 6.

4 Татарда нинди җырчы бар?

а) Фәүзия Мадрид;
б) Фирүзә Париж;
в) Фәния Берлин.

Җаваплар: 1. в); 2. а); 3. а); 4. б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 351

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+